**Бөтендөнья татар конгрессының**

**киңәйтелгән утырышы**

*(“Казан” милли мәдәният үзәге)*

**29.11.2017** **Казан шәһәре**

**Васил Шәйхразиев:** Хәерле көн, хөрмәтле милләттәшләр, бүгенге утырышта катнашучылар! Бөтендөнья татар конгрессының киңәйтелгән утырышын башлап җибәрергә рөхсәт итегез.

Бүген иртә белән без шушы түгәрәк өстәлләр артында сөйләшеп, күп кенә үзебезгә кирәкле һәм файдалы эшләр турында сөйләштек. Шул ук вакытта менә хәзер үзебезнең пленар утырышны башлыйбыз.

Бүгенге утырышта Россиянең 36 төбәгеннән һәм 13 чит илдән татар оешмалары һәм татар мәдәният үзәкләре җитәкчеләре катнаша. Шулай ук республиканың дәүләт структурасы вәкилләре дә биредә.

Безнең быел августта булган VI съезда зур үзгәрешләр, бер караганда, булды дип әйтә инде, ләкин безгә эшләр өчен ярдәм генә булырга тиеш. Шушы съезд вакытында без Милли Шура сайлап алдык. Аның рәисе итеп Рөстәм Нургалиевич мине тәкъдим иткәч, безнең делегатлар сайладылар, хупладылар. Шуңа күрә, беренчедән, үземнең бик зур рәхмәтемне әйтәсем килә, һәм августтан башлап, минем үземнең төп вазыйфалардан башка милләтебез өчен эшләү – иң зур вазыйфаларның берсе. Президентыбыз Рөстәм Нургалиевич әйтте: “Васил, син бирелеп, бөтен булган вакытың белән, Премьер-министр урынбасары буларак, вазыйфаларың буенча шунда эшләргә тиеш”, -дип.

Менә шул вакыттан бирле Казанга кайтып кергән вакыт та юк инде. Хәзер без Сахалинда, Владивостокта, Байкалда, Алтайда, Үзбәкстанда, Казакъстан һәм якын-тирәдә очрашып, мин үз күзләрем белән күрәм, безнең оешмалар ничек эшли, безнең татар җитәкчеләренең шәһәр күләмендә, өлкәләр күләмендә нинди авторитетлары бар. Менә бу әйтеп чыккан безнең өлкәләр буенча шаккатамһәм горурлыктан башка бүтән әйберләр юк әле. Безнең күтәрелгән һәрбер сораулар күп кенә вакытта тормышка ашыруны табалар, яки бүтән елга, айларга планнарга керәләр. Әле “юк” дип

берсе дә чыгарып борып җибәргәннәре юк. яки бик матур сөйләп, майларга маташалар, яки инде хактан да эшлибез дип, үзләренең ярдәмчеләренә шундый карарлар биреп, безнең автономия җитәкчеләре белән эшли башлыйлар.

Шуңа күрә менә шушы эшне алып барабыз. Тагын бер тапкыр әйтәсем килә. Быел мәктәпләрдә татар теле укыту буенча безнең күп кенә сөйләшүләр булды. Һәм Бөтендөнья татар конгрессы моннан читтә калмады. Без иң беренче булып үзебезнең фикеребезне карар итеп игълан иттек. Шул ук вакытта бүген безнең Дәүләт Советы сессиясе булды. Шушы сессиядә Республика прокуроры чыгыш ясады. Дәүләт Советы татарча укыту буенча безнең мәктәпләрдә, Республика күләмендә карарын кабул итте. Ул бүген Дәүләт Советы рәисе Фәрит Хәйруллович белән имза куйганнан соң, безнең бөтен газетларда чыгачак. Шуңа күрә менә шушы карар кабул иткән буенча һәм министрлыклар буенча безнең яңа эшләр барачак бу стандартлар буенча.

Безнең уйлавыбызча бу эшнең яки сорауның очына барып җитү, беренчедән, без үзебезнең телебез турында, мәктәпләрдә уку турында әйттек инде. Ләкин бу федеральный стандартлар мәктәпләрдә укыту турында гына сөйләнә. Шуңа күрә үзебезнең көндәлек тормышта татарча сөйләшү, алып бару, күп кенә кирәк булган бәйрәмнәрне, сөйләшүләрне, укуларны, тәрбия итүләр, телләр, дин – бөтенесе дә бездә калачак. Һәм менә дин дигәндә тагын әйтәсем килә, безнең мөфтиебез Камил хәзрәт һәрвакытта да әйтә, татар телендә вәгазьләр уку, догалар уку бөтен мәдрәсәләр буенча дип. Әгәр дә без бергәләп алып баралсак, телебез дә булыр, милләтебез дә булыр, динебез дә булыр. Шушы эшләр буенча алга барабыз.

Хөрмәтле җитәкчеләр, милләттәшләр, безнең бүгенге пленар утырышта без күп кенә җитәкчеләребезне монда трибунага чакыртып, аларның ничек эшләүләре, үрнәкләре турында безгә җиткерүләрен сорар идек. Әгәр дә мөмкин булса, 5нче 15 минутта бетерергә сүзем бар иде. Чөнки минем 16.30 Премьер-министр куламында зур совещание була. Шунда мин булырга тиеш. Әгәр дә без, хактан да, ныклап сөйләшеп, туктап булмаса, мин, рәис буларак, бер караганда регламентны да аласы килә, шуңа күрә чыгыш ясаучылардан

үтенеп сорыйм, әгәр дә сез 5 минут эчендә сөйләшеп бетерә алмасагыз, мин яки туктатам, яки сезнең арттан чыгасы җитәкченең сез вакытын ала башлыйсыз. Шуңа күрә бер-беребезгә зур ихтирамлы булыйк,

Иң башта мин **Ринат Зиннуровичка** үземнең сүземне бирер идем. Безнең августта зур чыгыш булды һәм бөтен эшләгән турында сөйләштек. Шуңа  күрә Ринат Зиннурович, аларны кагылмыйча гына безнең халкыбызга, җитәкчеләребезгә информация бирегез әле. Рәхим итегез!

**Ринат Закиров**: Рәхмәт! Әйе, бүген мин доклад сөйләргә җыенмыйм. Чөнки конгресснаң докладын без сезнең белән инде август аенда тыңладык. Быелгы эш елында нинди мәсьәләләр төп мәсьәләләр булып торган һәм киләсе 2018 елга кабул ителәчәк планны нигезләү һәм кайбер мәсьәләләргә игътибарны юнәлтү өчен мин бирегә чыктым.

Башкарма комитетның эше турында әйткәндә, без тулаем бер система турында сөйлибез. Чөнки күп еллардан бирле ул бер системага корылган иде. Ул системаның барлык әйберләре безгә мәгълүм. Ләкин аларга игътибарны юнәлтергә кирәк дип саныйм. Чөнки күп кенә мәсьәләләр әле безнең шул Казанда уздырылган зур Бөтенроссия, Бөтендөнья чаралары буларак, уздырылган чаралардан ары китәлми. Шундый мәсьәләләргә игътибарны күбрәк юнәлтергә дип уйлыйм мин. Чөнки без сезнең белән эш системасын инде шактый итеп кырдык.

Сездән килгән хатларга Башкарма комитетның игътибары искиткеч зур дип әйтергә мин җөрьәт итәм. Чөнки нинди генә хат килмәсен сездән, без ул хатларга бөтен коллектив белән игътибар бирәбез. Ул нинди дә булса үтә торган чарамы ул сездәге, юбилеймы, Казаннан кешеләр чакырумы һ.б. Нинди генә мәсьәлә чыкмасын, бу залда утыручыларның берсе дә менә минем хатка игътибар юк дип әйтергә булдыра алмый торгандыр дип уйлыйм, чөнки, чыннан да, әгәр дә ул хат тиешле дәрәҗәдә, тиешле срокларда, тиешле тәртиптә җибәрелгән икән ,аңа игътибар бездә һәрвакыт зур.

Шуңа күрә шушы хатлар аркылы без сезенң белән элемтәләрне тотабыз. Телефоннан шалтратып, безгә моны җибәрегез дип кенә әйтеп

булмый. Андый чакта хатыгыз кайда дип кенә сорыйм, чөнки, чыннан да, аппарат эчендә хат аркылы эшләү туры системага корылган. Шуның өчен ул контрольдә. Ә контрольдә булган әйберләрнең һәрберсе башкарыла. Бер чараны да башкармыйча калганыбыз юк.

Бу мәсьәләдә регуляр рәвештә безнең хәзер Президиум утырышлары кварталга бер, бюро утырышлары ай саен бара. шулай ук күчмә утырышлар. Без быелгы планга кергән күчмә утырышларның да барсын да башкардык. Кайларга барганны сез беләсез: Түбән Кама, Курган өлкәләрендә.

Менә шушы системалы эшләүнең тагын бер юлы – ул төрле төркемнәр белән эшләү. Без шактый саллы гына яшьләр белән эшләүне кора алдык сезнең белән. Йөздән артык яшьләр оешмалары булуы, күп оешмаларның кырында яшьләр оешмалары барлыкка килде. Шуның белән бергә без Бөтендөнья татар конгрессы каршында Бөтендөнья яшьләр форумының эшчәнлеге дә планга нигезләнгән. Аларның үзләренең формалары, Казанда бик күп чараларны уздыралар. Һәм, әлбәттә, сезнең үзегездә системалы эшләүгә корылган чараларда катнашу аларның шулай ук вазыйфасына керә. Монда мин әйтер идем Новосибирскиларның һәр елны Себер яшьләрен җыюларын.

Төрле төбәкләрдә елдан-ел яшьләр оешмлары активлаша бара. Әлбәттә, Казаннан чакырып, менә шушы зур чараларны бергәләшеп, тирә-яктагы төбәкләрдән дә чакырып, зурайту соңгы елларда күзәтелә андый әйбер. Гомумән, һәрбер чарага, әгәр дә аның масштабларының үсүен телисең икән, Казаннан вәкилләр чакыру бер әйбер, ә менә тирә-як күршедән, тирә-яклардагы төбәкләрдән, илләрдән кешеләрне чакыру ул чараларны эзлеклерәк һәм зуррак, масштаблырак итеп оештырырга мөмкинлек бирә. Шул ук вакытта читтән кунаклар күбрәк килгән саен, үзеңнең төбәктәге милләттәшләр арасында да, хакимиятләр алдында да аның дәрәҗәсе, абруе үсә бара. Бу турыда безнең инде сөйләшкәнебез бар. Шуңа күрә мондый юнәлештәге эшләрне без хуплыйбыз, яшьләр эшләрен дә, хатын-кызлар эшләрен дә. Нинди генә мөнәсәбәттә булмасын, без мондый эшләрне хуплыйбыз. Шушы юнәлештә эшләп, безнең 3 ел элек Бөтен Европа Альянсы

төзелде. Бөтен Европадагы дәүләтләрдә яшәгән милләттәшләребезнең бер еошмага туплануы да менә шушы юнәлештәге эшләрнең нәтиҗәсе дип саныйм.

Әйткәнемчә инде, хатын-кызлар хәрәкәтенең бик актив үсүе турында без әйтергә тиешбез. “Ак калфак” оешмасының бик зур эшчәнлеге. Сез үзегез дә булдырасыз, һәр төбәктә бер 2 ел эчендә әйтик, хатын-кызлар оешмалары бик актив барлыкка килде. Яшьләр ул яктан әле калышалар. Әле безнең бу мәсьәләдә эшлисе эшләребез бик күп. Менә хатын-кызлар өлгерерәк булып чыкты. Оешмалар чүпрәдә үскән кебек, һәр көнне, һәр атнаны, һәр айны яңадан яңа оешмалар барлыкка килә. ул оешмалар барлыкка килүе – ул бер яктан, икенче яктан, эшләгән конкрет эшләре дә күп.

Төрле төбәкләрдә мастер-класслар уздырулар, ул нинди мәсьәләгә кагылган булмасын, безнең әле тавык чүпләп бетермәслек эшләребез шушы хатын-кызлар оешмалары аркылы барырга тиеш. Бу безнең йолаларыбызны, гореф-гадәтләребезне торгызу, татар ашларын, татар милли киемнәрен һ.б. Чыннан да, монда искиткеч зур масштаб. Әгәр дә без шуларны яшь буынга, балаларга сеңдерә алырлык дәрәҗәдә эшне куя алабыз икән, димәк безнең киләчәктә милли йөзебез барлыкка килү мөмкин. Без күп әйберләрне югалткан рәвештә аны торгызу белән шөгыльләнәбез. Быел гына да Татарстанда “Татар ашлары” буенча зур мастер-класс  үтте (250гә якын кеше катнашты).

Һәр елны без үткәрелә торган зур системалы чаралар турында әйтеп тә тормыйм мин. Сабантуйлар – ул барыбыз өчен дә изге бәйрәм, милли бәйрәмнәрнең иң иңе. Ләкин минем әйтәсем килә бер генә мәсьәлә – Сабантуй үткәрмәгән оешма безнең юк дип әйтергә була. Ләкин Федераль Сабантуйлар проекты, Бөтенроссия авыл Сабантуйлары проекты, мин игътибарыгызны юнәлтәсем килә, анда без һәр елны 500 кешене шушы төбәкләрнең кабул итүен алдан сөйләшеп, кемнәр кабул итә, кемнәр оештыра, кемнәр чакыра, кая урнаштыралар – бөтенесен бәйнә-бәйнә сөйләшкәннән соң, соңгы вакытта 350 кеше килгәч, бик күңелсез була.

Бу ялкаулык дип әйтимме, нindidер чир дип әйтимме, әйдә, миннән башка да узар әле дип уйлаумы. Әгәр дә ни дәрәҗәдә кирәклеген, милләтеңнең зурлыгын күрсәтә торган чараның барына да кагылганын аңламыйсың икән, селкенеп йөрүдән мәгънә юк үзеңдә Сабантуй оештырып кына.

Бу Сабантуйларның уздыру даталары билгеле. Шуңа күрә дә үзегезнең Сабантуйларны да, калган чараларыгызны һ.б. алдан планлаштырыгыз. Мин бу мәсьәләдә бераз гына кырысрак та әйтергә мәҗбүрмен, чөнки уйлап карагыз, 500 кешене кабул итеп, урнаштырырга алынган хакимиятләр, инде шунда 100-150 кеше килеп җитми икән, бу бик матур күренеш түгел, безне бизәми. Шуның өчен дә алдан без билгелибез, алдан хәбәрләр җыябыз, шуңа күрә дә алдан билгеле, кем килә икән, заявкалар килгән икән, чыннан да, катнашырга кирәк.

Безнең һәр елны үткәрелә торган чаралардан “Татар кызы” бәйгесе, “Дин әһелләре” форумы, Изге Болгар җыеннары, “Татарча көрәш” турнирлары, “Түгәрәк уен” Бөтенроссия фольклор-фестивале. Бу шулай ук безнең Сабантуйларның милли йөзен булдырган өчен чаралар. Ул бер дә юктан уйлап чыгарылган әйбер түгел. Төбәк тарихын өйрәнүчеләрнең форумнары, фәнни-гамәли конференцияләр, төрле укулар. Андый укулар безнең 25 ләп бүгенге көндә. Яшьләрне югары уку йортларына укырга китерүне оештыру, мастер-класслар, әйткәнемчә, Президентның визитлары вакытында аның урындагы оешмаларның активлары белән очрашулар оештыру, оешмаларның юбилейлары, татар авылларының юбилейлары, төрле төбәкләрдә мәчет ачылышлары һ.б.

Мондый чараларны санап бетерерлек түгел. Һәрберсе безнең барыбызга да кагыла, яшьләр оешмасына гына түгел, дин оешмаларына да. Бик зур игътибар кирәк барыгыздан да. Әгәр дә сез безгә кагылмый дип йөрисез икән, бу бер дә дөрес түгел. Милләтебез дин юлына баскан икән, без сезнең белән шушы махсус дини оешмалар белән, мәхәлләләр белән, мөфтиләр белән кулга-кул тотынышып эшләргә кирәк.

Казанда уздырылган чаралар белән генә чикләнсәк, бу безнең өчен, әлбәттә, кызганыч. Шул ук Авыл эшмәкәрләре җыеннарын гына алыйк. Без эш юктан оештырылган әйберләр түгел. Әгәр дә татар авылларының киләәчге турында уйлыйбыз икән, безгә татар авыллары белән конкрет эшләргә кирәк. шушы эшмәкәрләрдән башка ул авылларның йөзен бүтән билгеләп булмый, аны беркем дә күтәрә алмый: хакимият тә, муниципаль берәмлекләр дә. Монда һәр авылдагы эшмәкәрләрнең активлыгын булдырып кына шушы авылларның йөзен саклап була.

Биредә без инде 9нчы тапкыр уздырабыз шушы Бөтенроссия татар авыллары эшмәкәрләре җыеннарын. Президент һәрберсендә катнашты. Һәрберсендә катнашып, бәйнә-бәйнә аларның проблемалары турында сөйләшә, ярдәм итү мәсьәләләрен карый. Әле безнең ничә төбәк кенә Чувашстан Республикасында авыл эшмәкәрләре җыеннары үтә, Пермь өлкәсе үткәрә башлады, безнең Хавыев. Андый мисаллар әле бик сирәк. Шуңа күрә оешма җитәкчеләренә мөрәҗәгать итеп әйтәм, Омск, Красноярск калаларында, Екатеринбург – һәрберсендә 50шәр, 60шар, 70шәр татар авыллары. Эшләргә дә эшләргә әле бу авыллар белән.

Ләкин эзлекле иттереп, шушы мәсьәләләрне күтәреп, оешмалар әгәр дә шушы әйберләрне оештыра алалар икән, монда шушында эшләүче эшмәкәрләрнең активлыгын оештырырга кирәк беренчедән. Алар үзләре оешса гына моны оештырып була. Шуның өчен бу мәсьәләләрдә без активрак булсак иде.

Киләсе елга планнарны сез кулыгызга алдыгыз. Быел каралган планнардан 100 берәмлеккә артык бирегә кергән чаралар. Ә бирегә чараларны без сезнең тәкъдимнәр белән кертәбез. Монда Бөтендөнья татар конгрессы һәр елны оештыра торган зур чаралар да кергән һәм шуның белән бергә без сезнең планнардан иң дәрәҗәле һәм безнең милләтебезгә йогынтысы көчле булган чараларны сайлап алабыз. Менә шул юл белән сайлап алынган чаралар бүген шушы планның проекты буларак сезгә тәкъдим ителгән. Әгәр дә әлеге планга сезнең нәрсәдер булса да кермәгән

икән, әле тәкъдимнәрне бирергә мөмкин. Без аны бүген раслаганнан соң, тагын берәр атнадан гына күябыз. Шул атна эчендә үзгәртергә дә мөмкин.

Әгәр дә Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитетын үзегезнең төбәкләрдәге ниндидер зур чараларда тагын да масштаблырак итеп уздырыр өчен катнаштырасыгыз килә икән, рәхим итегез, без яңадан карарга әзер. Киләсе елга бурычлардан, мин берничә мөһим эшләргә сезнең игътибарны юнәлтәсем килә. Һәр төбәктә яшьләр оешмасы булырга тиеш. Яңадан бу мәсьәләгә кайтып, ниндидер аңлатулар кабул ителми, белеп торыгыз. Татар яшьләре белән эшләмәгән оешманың киләчәге юк.

Шулай ук татар авылларын җанландыру. Һәр төбәктә, бигрәк тә татар авыллары күп булган, Идел буендагы өлкәләрне әйтмим дә инде, Самара, Ульян, Әстерхан, Волгоград, Мордовия, Удмуртия һ.б. Ә менә себердә татар авыллары тулып ята. Иртышның буеннан буена ничә өлкәгә таралган татар авыллары бүгенге көндә ярдәм көтә, сезнең игътибарны көтә, һәм, әлбәттә, бергә берләшкәндә генә, ул авылларның киләчәген булдырырга һәм сакларга мөмкин булачак.

Шулай ук “Ак калфак” оешмасының эшчәнлеге турында да әйтем бая. Сездән зур игътибар кирәк хатын-кызлар оешмаларының эшчәнлегенә. Аны тулысынча файдаланырга кирәк, милләтебезне тәрбияләү эшендә, бигрәк тә яшь буынны тәрбияләүдә.

Эре бизнес вәкилләре, эшмәкәрләр белән эшләү. Без күптән инде бу турыда әйтеп киләбез. Сабантуй җиткәндә генә эшмәкәрләргә мөрәҗәгать итеп, әйдә акча бирегез дип әйтү – ул бик урынлы түгел. Күп җирләрдә шуның аркасында конфликт килеп чыга. Эшмәкәрлә әйтә: “Без нишләп бирергә тиеш?”, -дип. Ә менә Сабантуйлар үткәргәндәме, башка зур чаралар үткәргәндәме үзләренең акчаларын кертүен телисез икән, аларның клубларын булдырырга, аларның төрле чараларын уздырырга һәм якынаерга кирәк. Бергә берләшкәндә генә, бергә буланда гына бу эшмәкәрләрне коллектив рәвештә зур проектларга ярдәм итәчәкләре көн кебек ачык. Менә Ульян каласындагы Сембер клубы инде дистә елга якын эшли. Менә шушындый клубларны, аның мисалы бар, һәрбер җирдә: Әстерхан,

Оренбург, Саранск, Ульян калаларында эшмәкәрләр берләште. Калган җирләрдә менә шундый ук эшләр булса, бик әйбәт булыр иде дип уйлыйм.

“Ана теле” проекты. Нинди зур акчаларга Президент ярдәме белән читтәге милләттәшләребез өчен төзелгән проект бу. Бик авырлык белән бара. Мәгариф министрлыгына заявкалар, төрле тәкъдимнәр җыйганда, һәрберегездән без яңадан сорап чыгабыз. Кулланырга кирәк “Ана теле” белән. Әгәр дә бүгенге көндә, бүгенге заманда туган тел буенча авырлыклар килеп чыккан заманда бу бигрәк тә кирәк. Бу өстәмә булдырылган система. “Ана теле” проектын үткән кеше үзлегеннән дә телне чарлый ала һәм киләчәктә дә куллана ала.

“Татар кызы” бәйгесен әйттем мин сезгә. Авыл эшмәкәрләрен әйттем. “Татар ашлары” көннәре планнарда. 19 төбәктә генә “Татар ашлары” көннәре планнарга кертелгән.  “Татар кызы” бәйгесе шулай ук 19 төбәктә. Без быел инде 28 төбәктә уздырган идек. Киләсе елда 19 төбәк планлаштыра. Бу нәрсә? Моны саңга сукмаумы. Әгәр дә “Татар кызы” бәйгесенең яшь буынны тәрбияләүдәге ролен күрмәгән булсак, без аны алай кертеп, азапланмаган да булыр идек.

Без сезнең белән бу бәйрәмне, бу бәйгене Сабантуйлар дәрәҗәсенә күтәрергә тиешбез. Әгәр дә без кызларыбыз аркылы, милләтебезнең иң асыл сыйфатларын, бигрәк тә туган телне камил белгән кызларны сәхнәгә мендереп, бөтен милләтең белән зурлыйсың икән, бу, әлбәттә, безнең киләчәгебез дигән сүз. Шуның өчен моны ниндидер бер вазыйфа итеп кенә санамагыз, һәрберегезгә бүген моннан кайтканнан соң, планнарыгызны карагыз да, яңадан җибәрегез.

Без киләсе елга һәр оешма үткәрергә тиеш дип саныйбыз “Татар кызы” бәйгесен, һәр оешма “Ана теле” проекты белән шөгыльләнергә тиеш. Һәр оешма яшьләр проектын хуплап, алар быел уздырган “Татарча диктант”ны киләсе елга бөтен милләтебез белән язачакбыз, белеп торыгыз. “Татарча диктант” ноябрь аенда. Һәр төбәктә утыртып, биналар алып, яшьләрне җыеп, үзегез утырып, диктант язырга өйрәнәбез. Рәхмәт сезгә!

**Васил Шәйхразиев:** Рәхмәт! Менә минем уң якта Ринат Зиннурович утыра, сул якта Илдар Ирекович утыра. Шуңа күрә мин 5 минут эчендә генә **Илдар Ирековичның** чыгыш ясавын сорар идем. Рәхим итегез!

**Илдар Гыйльметдинов**: Васил Гаязович, бик зур рәхмәт! Хөрмәтле коллегалар, мин инде федераль автономиянең эшчәнлеге турында сезгә сөйләргә җыенмыйм. Монда утырган автономия җитәкчеләренең бер өлеше белән без әле сентябрь аенда гына Кырымда очраштык. Үзебезнең эшләү юнәлешләрен билгеләдек. Шуңа күрә без гел аралашып торабыз һәрдаим рәвештә.

Безнең төп бурыч – аларга ярдәм итү, аларны өйрәтү. Ниндидер задание генә бирү түгел, алай гына эшләп булмый. Шуңа күрә иң беренче чиратта регионнарга мөмкин булган кадәр ярдәм итәргә кирәк, аларның эшчәнлегендә, аларның шундагы җирле хакимият җитәкчеләре белән аралашуында. Менә безнең төп эш шул. Монысы бер.

Икенчедән, Васил Гаязович, минем бер соравым бар. Бу конгресс вакытында күп кенә тәкъдимнәр белән чыктык. Эшне яктырту буенча, кайбер вакытта критикалаган көннәр дә булды, аларны безгә анализлап, бер шуларны тормышка ашыра торган эш программасын булдырырга кирәк. Алай булмаса, без һәр елны менә шулай чыгып сөйлиячәкбез, зарланачакбыз, яки тәкъдимнәр әйтәчәкбез, шуның белән шулай кәгазьдә калачак. Алай кирәкми, минемчә. Шул тәкъдимнәрне анализлап, хәл итү юлларын уйларга кирәк. Монысы икенчесе.

Өченчесе, соңгысы. Тел буенча әйтә алмыйча булдыра алмыйм. Чөнки ул безнең менә мин Дәүләт Дума комитеты рәисе буларак та, төп эшләребезнең берсе – без якын арада Мәскәүдә, яңа елдан соң булыр инде ул, аңа кадәр вакыт калмады хәзер, Парламент укулары уздырырга җыенабыз туган телләр буенча. Аңа әзерләнәбез. Инде регионнардан бик күп кенә тәкъдимнәр алдык. Һәм шушы тәкъдимнәрне туплап, 23 ноябрь көнне мин мәгариф министрына ул тәкъдимнәрне җибәрдем. 22 пунктан тора.

Без хәзерге вакытта тынычланып, хәл итеп бетерәбез инде дигән фикердә генә калырга тиеш түгел. Чөнки туган телләрне һәм дәүләт телләрен

укыту улл комплексы, бөтен яктан каралырга тиеш, һәм федераль үзәк бу мәсьәлә белән шөгыльләнергә тиеш. Ә регионнарның үзләренә генә, менә теләсә нишләгез, тел белән шөгыльләнегез дип әйтергә тиеш түгел. Шуңа күрә 2 пункт, мин аларны русча яздым. Бер-икесен генә укып китим, аңлавыгыз өчен, нинди тирән һәм нинди катлаулы бу мәсьәләләр.

Аларны хәл итү республикалар, регионнар үзләре гнеә шөгыльләнергә тиеш түгел дигән фикерне әйтәсем килә. Әгәр дә без бөтен ил буенча бердәм мәгариф системасы дип сөйлибез икән, значит ул шулай булырга тиеш. Безнең законнарда да, конституциядә каралган, дәүләт бирә гарантия телләрне саклау һәм укыту буенча. Ә ул гарантияне тормышка ашыру өчен иң беренче чиратта комплекслы программалар булырга тиеш. Без инде моны берничә ел сөйләп киләбез. Кызганычка каршы, очына барып чыга алганыбыз юк. Берничә фикерне генә әйтәм.

- Проработать вопросы создания и поддержки системы онлайн обучения родным языкам
- Рассмотреть возможность ежегодного проведения Всероссийской научно-практической конференции, посвященной Международному дню родного языка
- Разработать план мероприятий по преодолению сокращений количества ученых и научных коллективов, занимающихся изучением языков
- Министерству образования и науки с Российской Академией провести анализ достаточных современных образовательных услуг дополнительного образования, обратив особое внимание на детей, проживающих в сельских местностях
- Правительству Российской Федерации совместно с Академией наук представить предложения по повышению эффективности фундаментальных научных исследований в сфере сохранения и развития языков народов

- Обеспечит бесплатную довузовскую подготовку и иные льготы для приема абитуриентов в образовательные организации высшего образования по группе специальности “Языкознание”
- Разработать меры по совершенствованию системы педагогического образования, системы подготовки учителей по родным языкам народов России, подготовка специалистов для работы с двуязычными обучающимися
- Подготовить предложения по проведению региональных и межрегиональных фестивалей языков
- Разработать и реализовать меры по совершенствованию системы мониторинга состояния развития языков народов Российской Федерации
- Подготовить предложения по возрождению Института национальных школ (при Министерстве образовния)
- Рассмотреть вопрос о включении в перечень Всероссийской олимпиады школьников проведение олимпиад по государственным языкам субъектов Российской Федерации
- Рассмотреть вопросы создания Совета по этнокультурному образованию при Министерстве образования и науки РФ
- Рассмотреть вопрос о создании центра по методическому сопровождению и изучению языков народов РФ
- Проработать вопрос об усилении в федеральном уровне научно-экспертного методического обеспечения деятельности образовательных организаций субъектов Федерации в вопросах изучения, преподавания государственного языка РФ
- Обеспечить привлечение к написанию учебников по языкам народов России научные и образовательные организации высшего образования, расположенных в субъектах РФ и передать эти полномочия этим структурам
- Необходимо внести изменения в порядок формирования федерального перечня учебников, предусмотрев право на

проведение научно-педагогических экспертиз учреждением федерального подчинения, расположенных на территориях субъектов РФ

- Совершенствовать порядок формирования федерального перечня учебников, предусмотрев механизмы поддержки создания и издания учебников.

Бүгенге көндә бары тик 7 телдә генә туган телдә укыту китаплары бар. Тагын 24 телдә укытылган программаларның 17сенең бер китабы да юк федераль реестрда.

- Обеспечить нормативно инструктивно-методические внедрения обязательной предметной области родной язык и литература в образовательных программах начального общего, основного и среднего образования
- Разработать единые рекомендации по преподаванию изучения государственных родных языков общеобразовательных организаций субъектов Российской Федерации
- Рассмотреть вопрос о регламентации изучения государственных языков республики в новой редакции ФГОС и примерных программ.

Менә шундыйрак тәкъдимнәр. Төгәлләп, шуны әйтәсем килә. Менә шундый комплекслы рәвештә, әгәр дә без туган телләрне саклау мәсьәләсенә килмәсәк, һәм үзләренең регионнарын үзләренә генә калдырабыз икән бу мәсьәләне, без ерак бара алмыйбыз. Шуңа күрә безнең бурыч шушында әйтелгән тәкъдимнәрне ничек булса да безнең шушы мәгариф системасындагы кешеләргә җиткерергә һәм аларның үтәлүен тәэмин итәргә дигән фикерне әйтәсем килә.

Бу мәсьәлә регионнар тарафыннан күтәрелгән. Мин үзем уйлап чыгарган әйберләр түгел. Шуңа күрә шушы юнәлештә эшне алып барырга җыенабыз. Бик зур рәхмәт! Уңышлар барыгызга да.

**Васил Шәйхразиев:** Бик зур рәхмәт! Хактан да, тел мәсьәләсе чыккач, без иң беренче әйттек, безнең депутатларыбыз бар Дәүләт Советында һәм Думада. Илдар Ирекович – ул зур тәҗрибәле депутат. Бүгенге көндә комитет рәисе. Шуңа күрә аның монда карарын язган хатын уку безнең өчен бик дөрес дип аңлыйм. Һәм сез әйтә аласыз, Бөтендөнья татар конгрессы шушы язган хатыгызны министр өчен дә хупый. Әгәр дә мөмкин булса, җавап алганнан соң, икенче утырышларда безгә җиткерсәгез, бу көндәлек эш бик дөрес. Шуңа күрә сезгә бик зур рәхмәт!

Ә хәзер сүзне Ульяновск өлкәсе татар милли-мәдәни мохтарияте Башкарма комитеты рәисе **Сафин Рамис Фарук** улына бирелә. Рәхим итегез!

**Рамис Сафин:** Хәерле көн, хөрмәтле Президиум, хөрмәтле коллегалар! Бүген күбрәк тел турына сөйләнә. Мин дә үз чыгышымны телгә багышларга булдым, әлбәттә башка тармакларда да безнең проблемалар булса да. Туган телебезне өйрәнү һәм үстерү бүгенге шартларда һәр укытучының гына түгел, ә һәр атаның да, әби-бабайның да изге бурычына әйләнде. Чөнки бүгенге Россия шартларында дәүләтнең тел һәм мәгариф турындагы законнары белән бергә, аның төп законы Конституция дә бозыла башлады бугай. Алай гына да түгел, Халыкара хокук нигезләре, дөньякүләм килешүләрне һәм кеше хокукларын бозу да гадәти күренешкә әйләнеп бара.

Сер түгел, без инде үзебез дә моңа ияләшеп барабыз бугай. Югарыдан төшерелгән һәр күрсәтмәне, һәр боерыкны дәшми-тынмый гына йота барабыз бугай. Дөрес, соңгы вакытта “Татарстан Яңа гасыр” телеканалы тапшырулары аша без татар телен Татарстан мәктәпләрендә прокуратура тикшерүләре һәм башка милли республикалардан аермалы буларак, Татарстан җитәкчелегенең үз сүзен әйтергә тырышуын һәр төрле компромисслар эзләвен күреп торабыз.

Әле безгә, Республикадан читтә яшәүче татарларга, килеп ирешкән коры хәбәрләр буенча гына да тоеп торабыз. Бүген Татарстанга авыр. Биредәге дәүләт теленә чын мәгънәсендә куркыныч яный. Башкаларга караганда, Татарстанга Мәскәүдән искән җил икеләтә салкын булса, безгә,

Республикадан читтә яшәүче татарларга аның салкынлыгы 10-20 тапкырга артачак. Мин һәрвакыт әйтеп киләм, бу дәүләттә безгә татарларга яшәү җиңел булмаган. Хәзер дә җиңел түгел. Алга таба тагын да авыр булачак. Шуңа күрә безгә, Россия татарларына хәзер аеруча бердәм булу кирәк. Федераль органнарга хатлар, мөрәҗәгатьләр язып, татар телен якларга кирәк дип уйлыйм мин. тамчы тама-тама да, боз тишә диләр бит. Безнең үзебезнең Ульяновск татар милли мәдәни автономиясе октябрьнең 20дә Россия Президентына шул уңайдан мөрәҗәгать тә юллаган иде.

Бүгенге шартларда татар телен саклап калу өчен нәрсәләр эшләргә була соң? Моннан 10 элек кабул ителгән 309нчы Федераль закон нигезендә дәүләт гомум белем бирү стандартларыннан милли региональ компонент төшерелеп калдырылганнан соң, мәктәпләрнең уку-укыту планнарыннан ана теле дәресләренә бүлеп бирелгән сәгатьләр саны, әлбәттә, бермә-бер кимеде. Ләкин сәгатьләр саны аз дип зарланудан бернинди дә файда булмаячагын аңлап, без телне өйрәтү, балаларга туган телебезгә карата мәхәббәт, ихтирам хисе тәрбияләү юлларын эзли башладык.

Иң беренче һәм ышанычлы юл – ул, әлбәттә, татар мәктәбе булдыру. Өлкә губернатор ярдәмендә татар автономиясе тырышлыгы белән 2004 елда Димитровград шәһәрендә татар мәктәбе ачылды. Әлеге белем бирү оешмасында бүгенге көндә 260 тан артык бала укый. Быелгы елны әлеге мәктәпкә Габдулла Тукай исеме бирелде. Тагын шунысын да әйтәсе килә, әлеге мәктәптә ел саен мәктәп тәмамлаучылар 100% югары уку йортларына, бюджетлы урыннарга керәләр. Димәк, татар телендә уку беркемгә дә зыянга түгел. Укучылар арасында тәртип бозучылар исемлегендә бер генә бала да юк. Әлеге мәктәптә укырга теләүчеләр саны елдан-ел арта бара. Быел әлеге мәктәптә 2 беренче класс тупланды.

Ульяновск өлкәсе мәктәпләрендә бүгенге көндә 14765 татар баласы белем ала. Ни кызганыч, шуларның 35% бүгенге көндә татар телен өйрәнүдән мәхрүм. Моңа ата-аналар гаепле. Алар татар теле кирәкми дип баралар. Ә 65% дәресләрне факультативларда, түгәрәкләрдә һәм дәресләрдә өйрәнәләр. Шартлар тудырылса да, ата-аналар балаларының татар телен

өйрәнүен теләмиләр. Бүген өлкәнең 44 мәктәбендә татар теле предмет буларак 162 мәктәптә факультативларда һәм түгәрәкләрдә өйрәнелә. Татар теле укытучылары бүгенге көндә җитәрлек, дәреслекләр дә җитә. Бары тик ана-ананың битарафлыгы гына безне шикләндерә.

2011 елдан башлап, 2 елга бер тапкыр өлкәбезнең татар теле укытучылары съездларын үткәрү дә, мөгалимнәрнең эшенә яңа юнәлеш бирә. Алар моннан бик күп санда дәреслекләр, методик кулланмалар алып китәләр. Соңгы съездда өлкә губернаторы С.И.Морозов катнашты, чыгыш ясады һәм ана теле укытучыларына бүләкләр тапшырды.

Анда шулай ук Ульяновск өлкәсе белән Татарстан Республикасының мәгариф министрлыклары үзара килешүгә дә кул куйдылар. Шушы Шартнамә нигезендә аның 7 статьясында мондый сүзләр язылган “Ульяновск өлкәсе мәгариф һәм министрлыгы өлкәдә татар телен өйрәнү өчен шартлар тудыруны гарантияли” дип язылган. Шуңа күрә мин тагын бер кат рәхмәт әйтәсем килә Энгель Нәваповичка һәм министрлыкка шушы статьяны кертә алганнары өчен.

Озак еллардан бирле без Татарстанның Буа, Әлки, Саба һәм Апас районнарындагы мәктәпләр белән хезмәттәшлек итәбез. Бергәләшеп төрле конференцияләр, семинарлар уздырабыз. Татарстаннан килгән тәҗрибәле укытучылар, дәреслек авторлары безнең мөгалимәләргә остаханәләр ягъни мастер-класслар бирәләр. Танылган язучылар белән очрашулар да үткәрәләр.

Укучыларны дәреслекләр, матур әдәби әсәрләр белән тәэмин итүгә дә зур игътибар бирелә. Шуңа күрә мин форсаттан файдаланып, тагын бер тапкыр Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгына, Бөтендөнья татар конгрессына, Федераль татар милли мәдәни автономиясына һәм Татарстан Мәдәният министрлыгына зур рәхмәтемне җиткерәсем килә. Алар безнең фондыбызны һәр ел саен яңартып торалар.

Соңгы елларда мәктәпләрдә ана теле дәресләре сәгатьләре кимetelә башлагач, без эшне балалар бакчаларыннан башларга булдык. Казаннан методик кулланмалар кайтардык, федераль татар автономиясе эшләп килгән курчак театры һәм башка төрле өстәл уеннарын, рус-татар телендәге

мультфильмнарны балалар бакчаларына тараттык. Безнең бу башлангычны өлкәбезнең Мәгариф министрлыгы да хуплап чыкты. Минем нәрсә әйтәсем килә, мәктәптә дәресләр кыскартылса да, әле бакчаларда андый сәгатьләрне кыскарту юк. Шуңа күрә балалар бакчасында менә бу эшне башларга кирәк дип уйлыйм мин. Татар теле өйрәтүне бүгенге көндә якшәмбе мәктәпләре, мәчетләр каршында да оештырырга исәбебез бар алдагы елда, Аллаһ боерса.

Ни чарадан бичара дигәндәй, бүгенге көндә шундый мөмкинлекләрне файдаланып калырга кирәктер. “Мәктәптә булмаса, гаиләдә татарча сөйләшегез”, –диләр. Мин бу сүзләрне өнәп бетермим. Дөрес, өйдә татарча сөйләшсәң, бала аралашу телен, сөйләм телен өйрәнә. Ә меңъеллык бөек тарихыбыз, Г.Тукай, М.Җәлил кебек татар язучылары турында алар кайдан белергә тиеш? Бу турыда уйларга кирәк. Бу турыда алар бары тик мәктәптә генә белеп кайта алалар. Аларда милли горурлык хисе кайдан килергә тиеш?

Бүгенге Россиядә кайчандыр дәүләт тоткан 2 генә милләт бар. Аның берсе татарлар булса, икенчесе руслар. Шуңа күрә безнең балаларыбыз да мәктәптә шушы турыда белеп чыксыннар иде. Ә аларны белер өчен мәктәпләрдә татар теле һәм аның тарихы укытылырга тиеш дип саныйм. Татарстанда гына түгел, кан кардәшләребез яши торган һәр төбәктә шулай.

Хәтеремдә, без үскәндә ачлый-ялангачлыкны күргән әби-бабайлар заманаларның авырлыгына бирешмәс өчен: “Барсына да түзәрбез, сугыш кына булмасын”, -дип әйтә торганнар иде.  Хәзер безгә XXI гасыр буынына “барсына да түзәрбез, телне генә алмасыннар” диясе генә кала. Шунысын уйлыйсың да, куркыныч булып китә.

Еллар узгач та, безнең оныкларыбыз алдынла йөзебез кызармасын иде. 1552 елда Явыз Иван Казанны яулап алганда булган вакыйгаларга бүген бәя биреп, кайбер галимнәр “бабаларыбыз үзара тарткалашып, кайберләре дошманга сатылып, дәүләтләрен югалткан” дип сөйлиләр. Чыннан да шулай. Еллар, гасырлар узып, безнең оныкларыбыз да нәкъ менә безнең менә бу залда утыручылар турында XXI гасыр башында яшәүче әби-бабаларыбыз безнең туган телебезне дә дәүләт югалткан сыман саклап кала алмаганнар дип әйтмәсеннәр иде. Рәхмәт игътибарыгыз өчен!

**Васил Шәйхразиев:** Бик зур рәхмәт, Рәмис әфәнде! Менә бу үрнәк булды барыбызга да, 7 минутлык бик матур гына чыгыш булды. Ә хәзер сүзне Свердловск өлкәсе («Урал татарлары») татар конгрессы төбәк иҗтимагый оешмасы рәисе урынбасары **Сафиуллина Фәвия Әхтәм** кызына бирәбез. Рәхим итегез!

**Фәвия Сафиуллина:** Урал татарлары конгрессы эшчәнлеге турында бик күп әйберләр сөйләргә булыр иде. Әмма бүген безнең барыбызның да җанын борчыган бер мәсьәлә – ул тел мәсьәләсе. Фәүзия апа Бәйрәмованың җанга тия торган бер сүзе баштан чыкмый. “Уралның аръягына чыксаң, татар халкы бар, татар милләте юк”, - дигән иде ул бервакытны.

Мин Уралда яшәгән кеше буларак, минем бигрәк тә бу җаныма тия. Үзләрен татар дип санаучылар бар, татар фамилияле кешеләр күп, әмма туган телне өйрәнү хокукыннан мәхрүм булган татар балалары татар әдипләренең мирасын, телебезнең милли хәзинәсен белми тәрбияләнә.

Мин үзем татар милли мәктәбендә барлык фәннәрне дә ана телендә үзләштереп, М.Әмир, Г.Әбсәләмов, Н.Исәнбәт, М.Мәһдиев әсәрләрен укып тәрбияләнгән татар баласы. 36 ел буе чит төбәктә, урыс арасында гомер кичерсәм дә, татарча уйлыйм, татарча фикер йөртәм, татарча яшим. Милли мәктәптә татарча укуым миңа рус телендә ике югары белем алырга комачауламады. Рус телендәге текстларны бүген төзәтәм, дөреслим. Русларның кайдан беләсең бу кагыйдәләрне дип соравына, вы русский язык знали, а мы его изучали дип җавап бирәм.

Советлар чоры заманында милли мәктәпләрдә белем алучы татарлар Татарстанда гына түгел иде. Безнең Свердловск өлкәсенең көнбатыш төбәгендә туып үскән Илдус Хуҗин, Хафиз Галиев, Шәмси Шахмаев кебек милләттәшләребезнең иҗатларын безнең өлкәдә генә түгел, Татарстанда да беләләр. Ул чор татарлары кайда үсүләренә карамастан, татарча укый, яза, әдәби телдә аралаша. Бүгенге чор татар балалары мондый бәхеттән мәхрүм.

Кыскача гына статистикага күз салсак, 1989 елда Сверловск өлкәсендә урнашкан 40 татар авылының 23 мәктәбендә татар укытканнар. 2010 елда ул мәктәпләрнең саны 15кә калган иде. Дәресләр саны кыскарды. Мәдәният

министрлыгы татарлар күпләп яшәгән районнардагы мәгариф бүлекчәләре мәктәп директорлары белән тыгыз элемтәдә эшләү нәтиҗәсендә, татар телен укытучы мәктәпләр саны 20гә җитә. Оптимизация аркасында узган ел алар 19га калды. Аның каравы, 2010 елда татар телен фән буларак 458 бала өйрәнсә, бүгенге көндә аларның саны 729га җитте. Аннан тыш, шәһәрләрдә татар якшәмбе мәктәпләре эшләп килә. бүгенге көндә аларның саны 8. Якшәмбе мәктәпләрендә төрле яшьләрдә булган 200дән артык кеше йөри. Өлкәдә яшәүче 143 мең татар өчен бу диңгездәге тамчы гына.

Татар теле дәресләренең санын арттыру максатыннан җитәкчеләр белән эшләгәндә, без гел Татарстанны үрнәк итеп куя идек. Сүздә генә түгел. Ике төбәк арасындагы килешү нигезендә район хакимиятләре һәм мәгариф бүлеге җитәкчеләре Татарстанга тәҗрибә алмашырга дип алыпк илде. Казан шәһәрендәге лицей, гимназияләрдә һәм Кукмара районының берничә мәктәбендә булып кайттык. Шул вакытта төрле милләт балаларының чатнатып 4 телдә сөйләшүләрен күреп, шаккатып кайтканнар иде безнең җитәкчеләр.

Өлкәдә милли-мәгариф системасына җитәкчеләрнең азмы-күпме уңай караулары, елга бер тапкыр милли оешмаларга мәгариф системасының грантлар бирелүе, олимпиадалар, бәйгеләр, семинарлар уздыруы – болар барсы да Татарстанда булып кайтканнан соң, Республиканыңуңай мисалында барды кебек.

Июль ахырында Президент авызыннан чыккан сүзләрдән соң, әле пока күз тимәсен, безнең Свердловск өлкәсендә татар теле укыту буенча артык үзгәрешләр юк. Татар теле дәресләрен укыту саны кимемәде. Әмма укытучылар һәм мәктәп директорлары саклану чараларын күрделәр. Тиз арада ата-аналардан гаризалар җыеп алдылар. Сентябрь аенда ук Түбән Сырга авылындагы татар теле дәресләрен укыту планында “Грамматика родного языка” дип үзгәрттеләр. Әртә районында киңәшмә вакытында бер чиновник: “Татар телен өйрәнәсегез килсә, әнә Татарстанга барыгыз”, -дип әйткән. Укытучылар, татар теле укытучылары аңа без үз илебездә 500 еллык

тарихлы татар авылларында яшибез, хакыбыз бар дип, дәррәү каршы чыкканнар.

Сүз уңаеннан, Әртә районының Әҗегол авылы мәктәбе инде 110 елга якын тарихка ия һәм шуларның бер генә елы да татар теле дәресләресез укытылмаган. Бүген дә бу мәктәптә атнасына 3 сәгать татар теле һәм әдәбият дәресләре укытыла. Балалар арасында татар теле буенча халыкара олимпиадаларда җиңүчеләр һәм губернатор премияләренә ия булучылар бар.

Татарстандагы тел мәсьәләсе буенча бүгенге вәзгыять безне бик тирән борчуга сала. Казан, Татарстан безнең ватаныбыз. Татар халкының бишеге дип кабатларга яратабыз. Ни булса да, башларыбыз кыйблага борылгандай, Казанга борыла. Бүгенге Татарстан Дәүләт Советы утырышын күп өметләр баглап көттек без. Әмма нәтиҗә көтелгәнне бирдеме-юкмы, анысын тормыш күрсәтер. “Бизнес Онлайн” хәбәр иткәнчә, тел мәсьәләләре буенча карарның проекты бертавыштан кабул ителгән. Дәүләт теле буларак укыту программасында татар теле нибары 2 сәгатьтә калган. Хөкүмәт җитәкчеләренең, ил башлыгының бу четерекле мәсьәләдә алтын урталыкны таба алачагына чын күңелдән ышанасы килә.

Бүген әгәр татар теле дәресләре дисәләр, иртәгә татар балалар бакчаларын яба башласалар, аннан соң татарча массакүләм мәгълүмат чараларына җитсәләр, татарча газет-журналлар сезгә нәрсәгә, аны укый белүче юк, татарча телевидение нәрсәгә сезгә, аны аңлаучылар юк дия башласалар, без кая барып җитәрбез?

Шуңа күрә хөкүмәт җитәкчеләренә безнең тавышны ишетүне телибез. Без, дөньяга сибелеп яшәгән татарлар, Татарстанга таянып эш итәбез. Республика казанышларына горурланып яшибез. Татарстанның уңышлары чит җирләрдә татарларның абруен күтәрде. Төшермәгез бу дәрәҗәне, зинһар! Тел мәсьәләсе бит республикага гына кагылмый. Ул бөтен дөньяга сибелеп яшәгән татарларны милләт итеп саклаучы бердәнбер хәзинә. Ишетсеннәр иде безне.

**Васил Шәйхразиев:** Бик зур рәхмәт сезгә! Бик кирәкле чыгыш. Ә хәзер сүз Бөтендөнья татар конгрессының Литва Республикасындагы вәкиле,

Немежис татар җәмгыяте рәисе **Кузнецов Таир Сергей** улына бирелә. Рәхим итегез!

**Таир Кузнецов:** Здравствуйте, уважаемые братья и сестры! Во-первых, хочу поздравить вас с праздником. Сегодня у нас праздник. Это день рождения нашего Пророка (с.г.в.). Желаю всем здоровья и благополучия! Хочу поблагодарить руководство Татарстана и Всемирный конгресс татар за организацию Евро Сабантуя у нас в Литве.

Хотел бы продолжить свое выступление по поводу финансирования общественных организаций. Как я понимаю, вы все налогоплательщики, платите 100% и государство как бы должно заботиться об общественных организациях. О Литве говорят много. Но возьмем только то, что нам актуально.

В Литве по этому вопросу совсем по-другому. Каждому налогоплательщику дано 3%, где он может распределить их по своему усмотрению. Т.е. 1% подоходного налога налогоплательщик может отдать только политическим партиям. У нас политические партии не финансируются, с юридических лиц запрещено, а физическим лицам отведено только определенная сумма. И поэтому сейчас, как вы видите, наверное, из прессы, все содрогают скандальные происшествия с этим финансированием.

Что касается остальных 2%, то налогоплательщик может их распределить школам, детским садам, спортивным клубам, общественным организациям. Даже может разделить по частям: 1% школе, другой – общественной организации. Таким образом, у нас решается вопрос с финансированием общественной организации. Деньги большие-небольшие, но их вполне достаточно на административные расходы своим организациям.

Хотел бы сейчас перейти к самому больному вопросу. Это вопрос школы. Мое мнение такое – отними у человека веру и родной язык и он сам забудет о своем народе. Мы потеряли свой родной язык из-за того, что после Люблинской унии нам было запрещено употреблять татарский язык. И 620 лет – это 25 поколений в окружении христианского мира сохранить это было

очень трудно. Мы сохранились как этническая группа благодаря Всевышнему Аллаху. Хоть и утеряли язык, но не меньше мы татары, нежели говорящие на татарском языке. Правда, в самом Татарстане, в самой Казани очень много татар, которые не знают татарского языка.

Мы сейчас стоим на возрождении татарского языка. Мы это начали с учреждения культурных центров при помощи Евросоюза. Это у нас в общине построен культурный центр, самый большой в Прибалтике. Сейчас мы заканчиваем вторую часть его в гостинице. И именно на этой базе будет у нас возрождение татарского языка.

Сейчас, чтобы быть правдивым и вкратце, я хочу немного перейти к фактам, к статистике о школах у нас в Литве, которые могут быть заимствованы в Татарстане. Только что прозвучало из Президиума, что есть направления на национальные школы. Все данные взяты из статистического департамента и департамента национальных меньшинств за 2013-2016 годы.

Общее количество школ в Литве 1200. Общее количество учеников 357 тысяч свыше. Только литовских школ 1075. Польское население в Литве составляет 162 тысячи 344, польских школ 54 , учеников – 8446. Смешанные школы, литовско-польская - 11 школ, учеников около 3 тысяч. Польских учеников около 900. Русская и польская – 9 школ, учеников 3206, из них 2208 поляки. Литовская, русская, польские школы всего 6 школ. Свыше 2 тысяч учеников. Из них 3580 поляки. Всего в польских школах обучаются 11 тысяч 888 ученика.

В Вильнюсском университете есть стенд по изучению польского языка по программе «Польская филология». Очень часто меня спрашивают о положении русских в Литве. Русское население в Литве составляет 4 тысячи 610 человек. На русском языке есть 33 школы, 11837 учеников. Литовско-русские школы 14, всего 3260 учеников, из них русских около тысяча. Литовско-русско-польские школы из них русских свыше 1,5 тысячи. Всему русскому языку обучаются 14 тысяч 354 ученика.

В Литве действует ассоциация учителей русских школ. В Вильнюсском университете имеется кафедра русской филологии, в Институте иностранных

языков студенты имеют возможность обучаться по специальности «Русская филология и английский язык». В педагогическом университете имеется кафедра русской и кафедра белорусской филологии. Информационные издания. 12 газет. Такие газеты для информации «Обзор», «Пенсионеры», «Домашний доктор», «Кухня наша в Литве».

Что хочу сказать о других национальностях. Есть французская школа, где обучаются 112 учеников, английская школа – 196, литовско-английская школа 144. Количество проживающих немцев около 3 тысяч, одна гимназия, количество проживающих в Литве украинцев – 20 тысяч. Хочу отметить, что есть такая поговорка. Когда родился украинец, евреи заплакали, но получается так, что свыше 20 тысяч украинцев, но нет украинской речи, ни одной школы. Татар нас свыше 3 тысяч и одна воскресная школа.

Польское правительство уделяет большое внимание своим польским школам. Выпускники едут на льготных условиях в Польшу и получают дальнейшее образование. Тоже самое касается и евреев. По сравнению, например, как русская, насколько мне известно, таких привилегий получает мало.

Сейчас намечается ваш визит к нам. Я бы хотел, чтобы вы приехали к нам с делегацией, министром просвещения и культуры и ознакомились с этим положением. Как я понимаю из этого, что многие ссылаются, что Путин запрещает. Путин не запрещает в Татарстане иметь татарские школы. Нет проблемы никакой. Может быть татарская школа под одной крышей и русская школа. Насильно мил не будешь. Каждый пускай идет своей дорогой. Хочу подчеркнуть, Литве, чтобы занимать государственную должность, должен знать литовский язык. То же самое может быть и в Татарстане. Спасибо за внимание!

**Васил Шәйхразиев:** Бик зур рәхмәт сезгә! Ә хәзер сүзне Бөтендөнья татар конгрессының Пермь краендагы вәкиле **Назин Сәлим Нәҗип** улына бирәбез. Рәхим итегез!

**Сәлим Назин**: Хөрмәтле Президиум, хөрмәтле милләттәшләр! Пермь крае татарлары инде ничә гасыр татар телендә укыдылар. Әмма илдәге милли

сәясәт, дөнья күләмендә баручы глобальләшү безне читләтеп үтми. Пермь татарларының бүгенге көндә туган телебезне ничек белүе турында Бөтенроссия халык санын алу мәгълүматларына туктап итәм. Беренчесе. Менә күрәсез, 2002 елны безнең күпме халык татар телен белгән. 8 ел эчендә безнең татар телен белүче татарлар саны 28% кимегән.

Бу мәгълүмат билгеле булу белән, без күптән инде чаралар күрергә тиеш идек. Ләкин без татар җәмәгатьчеләре бу хәлгә тирән әһәмият бирмәдек. Милли хәрәкәт диңгез дулкыны шикелле, бер күтәрелә, бер сүлпәнләнә. Туган тел проблемасы кискенләшү безне дә читләтеп үтмәде. Бездә дә кайбер районнарда прокуратура хезмәткәрләре тикшерүләр үткәрде. Әлегә үз мәгълүматларын мәктәпләргә җиткермәделәр. Бүгенге хәлләрдән соң, бәлки алар да үз тәкъдимнәрен безгә җиткезерләр.

Без Пермь крае татарлары милли-мәдәни мохтарият утырышында туган телебезнең мәктәпләрдә ничек укытылуын карадык. Белгәнебезчә, Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгы Россия регионнарыннан этно-мәдәни татар мәгарифе торышы буенча мәгълүматлар җыя. Без татар телен өйрәнү мониторинг нигезендә анализ ясадык. Бүген күп кенә чыгыш ясаучылар шул ук мониторингка нигезләнеп, үз чыгышларын ясадылар.

Бу анализ безгә нәрсәләр ачыкларга ярдәм итте соң? Урыннарда без җәмәгатьчеләр, ата-аналар, мәктәп һәм балалар бакчасы җитәкчеләре мониторингка тиешле игътибар бирмибез. Мониторинг күрсәткечләре һәм дәүләт статистикасына бирелә торган форма ОО1 күрсәткечләре арасында аерма бар. Мониторингта мәгълүматлар тулы түгел, кызганычка каршы. Мониторинг дәүләт статистикасы дәрәҗәсенә җаваплы рәвештә күтәрелми. Белгечләр әйтүенчә, бүген дә ишетелде, бу мониторинг формасын әле яхшыртасы бар.

Пермь краенда этно-мәдәни татар компонентлы эчтәлекле белем бирү оешмалары саны 43. Ул мәктәпләрдә барлыгы 8120 бала укый һәм шуларның 7483 туган телләрне төрле формада үзләштерә. Бездә бу сан 90% күбрәк. Менә бу слайдта татар телен үзләштерү төрләре. Татар телен үзләштерүчеләр өлеше 92% булса, аны 2-3 сәгать формасында укучылар саны крайда 6647

бала, 81%. Факультатив рәвештә үзләштерүчеләр – 645, татар телендә генә укучылар саны 191 бала. Алар укыйлар ике мәктәптә, Тор-Түз авылында Хавыев Алмаз Альбертовичның туган ягында дип әйтергә кирәк. Менә анда башлангыч мәктәпләрдә  ике мәктәптә туган телдә укыталар. Татар телен өйрәнүчеләр, өйрәнмәүчеләр шушы балалар арасында инде 637, 8% тәшкил итә.

Беле бирү оешмалары хакында тукталып китсәк, ул слайд 5нче. Анда, әйткәнемчә, ике мәктәп бар татар телендә укыта торган. 31 мәктәптә татар теле дәрес буларак укытыла, һәм 9 мәктәптә факултатив рәвешендә укытыла. Бу безнең авыл җирлегендә урнашканнар. Авыл җирендә 39% гына яши татар халкының. Аның 61% шәһәрләрдә, ә шәһәрләрдә безнең 10 меңнән артык 18 яшькә хәтле балалар яшиләр. Аларга инде якшәмбе мәктәпләре бик түбән рәвештә оештырылган. Анда ике генә шәһәрдә хәзер якшәмбе мәктәбе бар, Пермь шәһәрендә һәм Губаха шәһәрендә. Һәм биредә укучылар саны бик әз. Алга таба безгә шушы якшәмбе мәктәпләренең ролен күтәрү өстендә эшләргә кирәк булачак дип күзаллыйбыз.

Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларына тукталасым килә. Мониторингта бу мәгълүмат төгәл түгел һәм анализ өчен җитәрлек дип санамыйм. Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларының саны безнең край буенча 17 һәм аларның 3дә генә татар группаларын күрсәтәләр. Алга таба бездә мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында туган телне өйрәнүче балалар санын күбәйтү өстендә эшләргә кирәк булачак. Мониторингта, мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында эшләүче хезмәткәрләр, тәрбиячеләр турында да мәгълүматлар юк.

Ул мониторингта укытучылар турында мәгълүматлар тулы рәвештә, ә балалар бакчасында эшләүче тәрбиячеләр һәм аларның җитәкчеләре турында инде белем җиткелек түгел. Ә тукталып китсәк, бу балалар балалар бакчасында, бигрәк тә тәрбиячеләр үз белемнәрен безнең рус педучилищеларныда алалар икән, алар килеп яңадан рус телендә генә тәрбия эшләрен алып баралар икән, менә монда безнең зур югалтулар бар.

Пермь крае буенча татар теле һәм әдәбияты дәреслекләре белән тәэмин ителү 85% тәшкил итә. Дәреслекләр белән тәэмин итүне күздә тотып, Пермь крае мәгариф министрлыгы менә шушы көннәрдә генә 2 миллион сумга яңадан заявка урнаштырды. Эшләр бара шикелле. Ләкин без бу эшләр белән бик канәгать түгелбез. Һәм алга таба инде шушы анализлар нигезендә туган телебезне саклау һәм үстерү буенча үз программабызны булдыру кирәк дигән фикергә килдек.

Безнең резолюция бар. Резолюциядә күп җирдә саклап калабыз дигән сүз йөри. Шуның белән беррәттән саклау белән үстерү дигән сүзләр сирәгрәк кулланыла. Безгә шушы сүзне мәгънәсенә басым ясап, үзебезнең резолюцияләрдә бик нык эшләргә кирәк дигән фикерем бар. Шушы тәкъдимнәрне тормышка ашыру өчен Пермь крае һәм Татарстан Республикасы Мәгариф министрлыгы арасында тыгыз элемтә булу мөһим.

Авырлыклар бар. Без “Татар мәгариф көннәре”н үткәргәләдек. Менә бу “Татар мәгариф көннәре” бүгенге көндә безнең таләпләргә туры килми дип әйтәсем килә. ул безнең семинар-совещание формасында үтәргә тиеш. Аның файдасы калсын, максатчан булсын һәм безнең укытучыларыбызны, тәрбиячеләребезне рухи көчләндереп, аларга методика, әсбаплар биреп, алга таба эшләргә булсын дип әйтәсем килә.

Без иртәгә Мәгариф министрлыгында очрашырга телибез. Тәмамлар алдыннан мин шунсын әйтер идем. Алга таба бигрәк тә мәктәпкәч белем бирү оешмаларында эшләүче тәрбиячеләрнең белемнәрен күтәрү буенча махсус эшләү кирәк булачак. Шулай ук алга таба татар балаларына һәм башка миләт балаларына белем бирү оешмалары уставларында аларның статусын дөрес билгеләү кирәк. Ул күп очракта дөрес билгеләнми, шуңа инде прокуратура һәм башка тикшерү органнарының кулланулары бар башка якка таба.

Хөрмәтле җәмәгать, телләрне белү һәрвакыт кешелек дөньясының, халыкларның үзара хезмәттәшлеген тәэмин итүче төп байлыгы булып санала. Ул интеллектуаль үсеш күрсәткече. Күпмилләтле Россиядә 3 тел белү нормага, кагыйдәгә керергә тиеш. Рәхмәт игътибарыгыз өчен!

**Васил Шәйхразиев:** Бик зур рәхмәт, Сәлим әфәнде! Хактан да төпле әзерләнеп килгәнсез, эш буенча, халык буенча, сан буенча. Без монда статистика ягыннан күрәбез, эшләгәнне күрәбез. Безнең, Аллабирса, менә мондый очрашулар булачак Казанда да, бүтән җирдә дә. Һәм өлкәдә эшләгән безнең җитәкчеләрне, актив вәкилләрне чакырабыз. Шул ук вакытта безнең тәҗрибә бар. Менә бәләкәй генә интерактив үткәрәсем килә минем.

Менә 15 көнне тагын барам Мәскәүгә, безнең анда вице-премьер бар Голодец Ольга Юрьевна. Мине спорт белән шөгыльләнгәч, дөрес тормыш алып баргач, бер ел элек шушы тема белән җитәкчеләр каршында Рәсәй күләмендә чыгыш ясарга сорадылар. Мин докладны яздым, килдем, менә шулай 150-160лап вице-губернаторлар, министрлар - бөтенесе утыра. Яшь белән барыбыз да бер инде, 40тан һәм өскәрәк.

Сәламәтлек дигәндә, безнең 3 әйбер бар. Беренчесе – ул шикәр. Кем үзенең канында күпме шикәр икәнен белә, кулыгызны күтәрегез әле. Бик зур рәхмәт! Ә нормасын кем белә яшькә карап? Бик зур рәхмәт! Икенче әйбер – ул холестерин. Кем белә күпме норма булганын? Бик зур рәхмәт! Ә үзенең нормасын кем белә? Һәм өченчесе, бик әйбәте, без 40тан соң һәр көнне иртә белән үзебезнең давлениены тикшерергә тиешбез. Кем шуны көн саен карап бара? Менә карап торабыз, менә шушы вакытта мөхтәрәм милләттәшләр, безнең залның 3/1 молодцы. Калганнарына тоже өйрәнергә кирәк.

Бер караганда без чыгып, һәрвакытта да әйтәбез, хактан да, татар телен якларга тиешбез, икенче караганда, ул бездән тора - гаилә телеме ул, дәүләт телеме ул. Менә мин кичә генә кайттым Финляндиядән. Безнең анда татар егете Финляндия татарлары, аның диаспорасы ничек булган, ничек бүгенге көндә һәм киләчәге турында фән докторы диссертациясен яклады иң зур университетларның берсендә. Яклау барды татар телендә. Үзенең оппоненты итеп Америкадан татар кешесен чакырганнар. Шамиль әфәнде – ул бүгенге көндә Астанда педагог булып эшли.

Финляндиянең иң зур университетларның берсендә татарларны җыеп, татар телендә сөйләшеп, татар халкы турында фән диссертациясе яклап утырабыз. Менә моны чын күңелдән, йөрәк аша үткәрегез әле– кем үз

гаиләсендә, өендә миртә белән уянганнан соң, хәерле иртә матурым дип, кичкә хәтле татарча сөйләшә? Кулларыгызны күтәрегез әле. Бик зур рәхмәт! Калганнарын әйтәбез инде 50/50%. Шуңа күрә әйтәсем килә, без кайвакытта килеп яки чыгып, халыкны өйрәтергә тырышабыз. Ләкин әгәр дә син үзең башламасаң, әгәр дә син дөньяны әйләндереп ясыйм дисәң, матур итеп үзеңнән башла. Синең гаиләң бар, балаларың бар, оныкларың бар, динең бар, күршеләрең бар, мәктәпләрең. Шуңа күрә без бөтен нәрсә буенча үзебез үрнәк. Финнар әйтә: “Без бакчага барган хәтле балаларга 24 сәгать буе татарча гына сөйлибез, татарча гына сөйләшәбез”, - ди. Алар балалар бакчасына баргач кына финча өйрәнә башлыйлар. Шуңа күрә без һәрвакытта да үзебезнең яктан карарга тиешбез.

Ә хәзер сүзне Кыргызстан Республикасының “Туган тел” татар-башкорт үзәге рәисе **Үлмәсколова Гөлсинә Хәйдәр** кызына бирәбез. Рәхим итегез!

**Гөлсинә Үлмәсколова:** Хөрмәтле Президиум әгъзалары, кадерле милләттәшләр! Мин сезне барыгызны да Кыргызстанда яшәгән татар халкыннан кайнар сәламнәремне алып килдем һәм сездән дә аларга кайнар сәламнәремне алып кайтырмын дип уйлыйм. Казанга килүем үз теләгем буенча түгел, татар халкы теләге буеенча килдем. Чөнки без барыбыз да хәзер телевизор тынлыйбыз, интернет карыйбыз. Һәм менә татар халкының, татар теленең нинди дәрәҗәгә төшкәнен күреп, безнең Кыргызстанда яшәүче татарлар бик нык борчылалар.

Без үзебез татар булып үстек, татар мәктәпләрендә укыдык, татарча матур сөйлибез, Кыргызстанда торсак, кыргызча сөйлибез матур итеп. Шуның өчен татар теле беренче булырга тиеш. Бездә анда Татарстаннан чыккан апалар бар, абыйлар бар. Шәүкәт абый килде дә, миңа әйтә: “Гөлсинә ханым, сез укыйсызмы, күрәсезме, ничек татар телен Татарстанда юкка чыгарырга телиләр”, -ди.

Без барсын да беләбез, хәзер килә башладылар, сөйли башладылар. Шулай итеп безнең оешмага җыелды 17 кеше, олы яшьтәгеләр, урта яшьтәгеләр. Әйдәгез барабыз Россия илчелеге ишеге янына. Сүз күтәрәбез,

ни өчен Татарстанда татар телен юкка чыгарырга телиләр дип. Без әйтәбез татар телен гаиләдә өйрәнергә кирәк дип. Дөрес, гаиләдә өйрәнергә кирәк беренче. Баланы без табабыз бит, тапкачтын да татарча сөйлибез бит. Татарча сөйләп, әгәр дә гаиләдә балаларны татарча өйрәтәбез икән, безнең балаларыбыз татарча беләчәкләр.

Менә минем үземнең 7 оныгым бар, 7се дә татарча сөйлиләр. Ирем дә сөйли, үзем дә сөйлим. Аннан соң әйтәләр, укыйлар да мәктәптә балалар татар телен, аннан соң кайда укырлар диләр. Мин үзем татар мәктәбендә татарча укып бетердем. Доярка булып эшләмим, дворник булып эшләмим. Әгәр дә татар теле укып, башы була икән. Ул бар җиргә дә укырга да керә ала, эшли дә ала. Нинди теләге бар, шул эштә эшли алачак.

Без Кыргызстанда яшәгән татарлар ни өчен татар теле өчен кайгырабыз, чөнки безнең татарыбызның бар җире Татарстан, бар безнең Президентыбыз, бар безнең флагыбыз, бар безнең гербыбыз. Шуңа күрә без Кыргызстанда горурланабыз, чөнки безнең дәрәҗәбез дә күтәрелә безнең үзебезнең илебез, үзебезнең җиребез булгач.

Абыйлар әйткән сүзләрне әйтмичә дә булдыра алмыйм. Шундый сүзләр йөри, имеш Татарстанда Президент дигән сүзне алып ташлыйлар дигән. Ул бит президент Татарстандагы татарларның гына президенты түгел, ул бөтен җир шарында яшәгән татарларның президенты. Татарстан да бит татарларныкы гына түгел, ә бөтен җир шарында яшәгән татарларның җире. Без шуның өчен горурланабыз, аның өчен без бик борчылабыз. Шушы сүзләргә игътибарыгызны салырга кирәк.

Мин аптырыйм, менә монда татар әниләре әйтәләр, нигә кирәк ул татар теле дип. Аны аңларга кирәк. Кем дә кем татар телен укый, татар телен белә, төрек телләрен барсын да аңлый, барсын да белә. Без бит белмибез, балаларыбыз кайда укырлар, кайда барырлар, нәрсә эшләр икәнен. Бәлки алар кайда төрек телләре белән эшлиләр, шул якка барулары бар. Алар татар теле белгән аркасында, төрек телләренең барсын да беләләр.

**Васил Шәйхразиев**: Әле бер көнне генә безнең Президентыбыз татар турында әйтте бит: "Әгәр дә син әни телен белсәң, син татар гына түгел, ә

төрекләр белән, үзбәкләр белән, кыргызлар белән, таҗиклар белән, кайвакыт кытайлар белән күп кенә 25, 30-35% аңлап, син бөтен нәрсәне эшли аласың. Бер караганда ул бөтен яклап та әйбәт. Сез дөрес әйтәсез. Рәхмәт.

**Гөлсинә Үлмәсколова**: Без Кыргызстанда яшәсәк тә, без Каюм Насыйри классы бар. Рәхмәт КФУга безгә ярдәм биргәннәре өчен, бездә аны ачулары өчен. Бүгенге көндә 38 бала укыйлар татар теленә. Безнең атнасына 4 сәгать керә. 4 сәгатькә дә киләләр. Татар балалары гына түгел, рус балалары да киләләр анда, кыргыз балалары да киләләр. Чөнки аларның әни-этиләре беләләр, ул балалар татар телен өйрәнә икән, белә икән, башка милләтләр белән дә сөйләшәләр, беләләр, сөйли алалар икәнен.

Ничек инде буз үз телебездән шикләнергә тиешбез? Ничек инде үз телебезне без яратмаска тиеш. Безнең татар теле иң матур тел. Татар халыклары иң матур халык, иң акыллы, иң булдыра торган халыклар. Исегездәме, Минтимер Шәрипович әйткән, “без булдырабыз” дигәнне. Безгә артка борылырга кирәкми, алга таба барырга кирәк.

Мин уйлыйм, безнең татар телебез югалырга тиеш түгел. Татар телебез югалса, безнең динебез дә югала, илебез дә югала, үзебез дә югалабыз. Ул бик куркыныч хәл. Шуның өчен мин үзебезгә кайткач, җыелышып әйтәчәкмен, аларның әйткән сүзләрен җиткердем, инде Татарстанда да татар теле югалмаячак дип кайтып әйтсәм буламы?

**Васил Шәйхразиев**: Була! Дөрес, Гөлсинә ханым. Бик зур рәхмәт!

**Гөлсинә Үлмәсколова:** Без сезне быел көткән идек 2 тапкыр. Сез килерсез дип уйлыйм. Чөнки сезнең килүегезне без, татар халкы гына түгел, Кыргызстандагы милләт халкы да көттеләр һәм көтәчәкләр дә. Сез безгә бик кирәк.

**Васил Шәйхразиев**: Аллабирса, декабрь аена мин планга керттем. Бу өченче тапкыр булгач, датасын әйтә алмыйм. Аллабиса, барып чыгарга тиеш дип уйлыйм. Литвага без барабыз гыйнвар азагында. Сездә декабрьдә булабыз, Аллабирса.

**Гөлсинә Үлмәсколова:** Без аның өчен куанабыз, көтеп калабыз сезне. Чөнки быел әйткән сүз икенчегә күчмәсен. Быел килердәй булсын иде. Аннан

минем әйтәсем килә, без бит инде татар халкы, монда балаларны җибәрәбез, укырга КФУга дип. Бөтен уку йортларыннан киләләр безгә тестирование үткәрергә. Шунда килгән вакытта конгресстан кем булса да, бер кеше килергә тиеш. Чөнки алар аннан киләләр дә КФУдан үзләренчә боралар араларны, үзләренчә ясыйлар. Әгәр дә конгресстан бер кеше килә икән, комиссия составында, алар аннан соң борыла да алмаслар. Татар телен беренче конгресс тота бит.

Элекке елларда 10 квота бирәләр иде татар балаларына, аннан 6га әйләнде. Менә ике ел эчендә бер бала да юк. Бирүче юк татар балаларына квота. Безнең “Каюм Насыйри”да татар балалары укый. Менә быел 3 бала укырга килсәләр, аларга бюджетка урын бирмәделәр. Бу мыскыллык, бу яхшылык түгел.

**Васил Шәйхразиев**: КФУга биргәннәр идеме? Әйдәгез тикшереп карыйбыз. Данил әфәнде яза да башлады инде.

**Гөлсинә Үлмәсколова:** Менә мин уйлыйм, ректор татар, проректор татар. Миңа шундый яман уй килде. Алар кәгазьдә генә татар булалар. Әгәр дә кем дә кем җитәкчеләр үзләрен татар дип саный икән, алар ничек булса да ул татар балаларына урын табарга тиешләр. Обязательно конгресстан бер кеше алар комиссия составында булырга тиеш. Менә быел комиссия килүчеләр бик начар булдылар. 3се дә түгел, берсе начар булды. Без балаларны алып киләбез, тестирование үткәрәләр, аннан миңа икенче көнне шалтраталар: “Менә мин министерство иностранных делда эшлиим. Мин баламны Татарстанга укырга җибәрергә дип уйлаган идем”. Менә мин алар белән утырсам, теге килгән комиссиянең берсе: “Наркоманмы?”, -диде. Белдегезме. Балаларны тестирование үткәрергә килгән комиссиянең берсен наркоманмы дип, министерство внутренних делдан шалтраталар. Мин әйтәм юк, юк, шулай үзе шутник кына, барсы да әйбәтләр димен.

Шуның өчен безгә тестирование җибәргән вакытта аңлы-белемле кешеләрне җибәрергә кирәк. Без чит җирдә торабыз. Безнең дәрәҗәне кирәкми төшерергә. Без Кыргызстанда яшибез, Алланың биргәненә шөкер. Беренче татарлар дәрес алып килгәннәр, дин алып килгәннәр. Шуның өчен

без үзебезнең татар халкын, Кыргызстанда яшәгән татарларны төшерәсебез килми. Шуңа күрә безгә җибәргәндә әзрәк уйлап килергә кирәк, уйлап кешеләрне җибәрергә кирәк. Чөнки без Кыргызстанда бүгенге көндә башка милләтләр арасында беренче урын алып торабыз.

Быел без “Алтайская цивилизация” дигән форум үткәрдек. Рөстәм Нургалиевич та килде анда. Килгәч, ул үтте резиденциягә. Ничә милләт бар, бер милләттән делегация чакырмадылар. Ә безнең оешмадан 10 делегация барды. Рөстәм Нургалиевич күрде аларны. Шуңа да әйтәм, безнең дәрәҗәнең биек булуы аркасында, татарларның бөеклеге аркасында анда булды.

Иссыккүлдә юрталар үткәрделәр. 8 милләт йорты ясалды. Беренче юрта булды кыргызларныкы, икенче – башкортларныкы, өченче – татарларныкы. Башкортныкын да, кыргызныкын да без үзебез ясадык, чөнки безнең татар-башкорт оешмасы. Без аларны ясадык та, башкортларга кереп чыкты инде Кыргызстан Президентыбыз, аннан соң, башкортныкыннан чыккач, Кыргызстанның Президенты делегация белән чыгалар бит инде: “Кара, әнә безнекеләр”, -ди. Кыргыз Президенты әйтә: “Әнә, безнекеләр, татарлар”, -ди. Кыргызстан Президенты да татарларны “безнекеләр” ди.

Без үзебез дә ул юртаны бик әйбәт ясадык. XIX гасырның башында ясаган тимер койкаларга хәтле алып килеп куйдык. Беренче урынны безнеке алды. Шуның өчен без куанабыз Кыргызстанда торганыбыз өчен. Комачаулый безне татар теле. Татар теле булырга тиеш, татар теле булсын. Рәхмәт барыгызга да!

**Васил Шәйхразиев**: Рәхмәт бик зур! Ә хәзер сүз Башкортстан Республикасы «Ак калфак» татар хатын-кызлар Ассоциациясе” иҗтимагый оешмасы Берлеге рәисе **Вафина Люция Ябир** кызына бирелә. Рәхим итегез!

**Люция Вафина:** Саумысыз, мөхтәрәм җәмәгать, газиз милләттәшләр!

Башкортстан, Русиядә Татарстаннан кала татарлар күпләп яшәгән икенче төбәк. 2010нчы елгы халык санын алу мәгълүматлары буенча бездә 1 миллион ярым татар яши. Бу республикада яшәүче халыкның өчтән бере дигән сүз.

“Ак калфак” Татар хатын-кызлар ассоциациясенең Башкортстан төбәк иҗтимагый оешмасы республикада үзенең таралган бүлекчәләре белән билгеле. Башкортстан районнарында “Ак калфак”ның 29 бүлеге эшли. Безнең конгресс каршында эшләп килүче Идрисова Кадрия Рәес кызы җитәкчелегендә Бөтендөнья татар хатын-кызлары “Ак калфак” иҗтимагый оешмасының дөнья буйлап 517 бүлекчәсе эшли. Без аерым план нигезендә эшлибез һәм ел саен еллык хисабыбызны тапшырабыз. Алдагы елга план төзибез. Безнең хисап менә шулай матурлап эшләнгән була. Бөтен төбәкләр дә аны эшлиләр.

Оешманың Игътибар үзәгендә МИЛЛИ гаиләләрне булдыру, саклау, ныгыту, илгә милли рухта, тәрбияле-белемле яшь буын тәрбияләү, телне, гореф-гадәтне, йолаларыбызны саклау, кире тарихыбызны барлау, шәҗәрәләрне өйрәнүгә басым ясау, милли киемнәребезне бүгенге көнгә ярашлы итеп куллану, үзебезгә хас аш-суны, тегү-чигүне, кул эшләрен өйрәнү һ.б. 2017 елның апрель аенда Казанда татар конгрессы һәм “Ак калфак” оешмасы үткәргән хатын-кызлар җыенында 600 гә якын делегат катнашты. Ә аннан тыш төрле регионнарда һәм Татарстан районнарында 5 күчмә утырыш үткәрелде.  Бу күчмә утырышларның һәрберсендә чит илләрдән, регионнардан, Татарстаннан 150 дән артык делегат катнашты. Һәр күчмә утырыш халкыбызның гореф-гадәтләренә, йолаларына, телебезгә, һөнәрләребезгә таянып, аерым тематика белән үтә. Өйрәтү буенча һөнәри дәресләр үткәрелә.  Шуңа күрә күчмә утырышларның безнең өчен файдасы бик зур. Залда утыручы оешма җитәкчеләренә әйтәсе килгән фикерем – үзегезнең “Ак калфак” җитәкчеләрен күчмә утырышы эшчәнлегеннән калдырмавыгызны сорыйм.

Ә без үзебез Бөтендөнья татар конгрессы каршында эшләп килүче “Ак калфак” хатын-кызлар оешмасы тарафыннан үткәрелгән күчмә утырышларда һәрдаим катнашабыз һәм анда алган өйрәнү дәресләрен үз җирлегебезгә кайтып таратабыз, мәгълүматларны җиткерәбез. Бу эштә гаиләләрдә балалар үстерү, тәрбияләү буенча К.Р.Идрисованың ике бүлекле диск “Тәрбия баскычлар”ы бик ярдәм итә.

Бүгенге көндә 1980-1990 елда туган балар әти-әни булдылар. Барыбыз да беләбез ул чорда татар телендә иркенләп сөйләшеп, аралашып булмый торган чак иде. Нәтиҗәдә бу яшь әти-әниләр дәүләт телен генә беләләр. Гаиләдә балар белән аралашу өчен дәүләт теле генә кулланыла.

Безгә беренче чиратта менә шул әти-әниләрне татар теленә мәхәббәт уяту кирәк. Бу юнәлештә без берничә проект белән эшлибез. 1- “Минем гаиләм туган телебез –татар телендә сөйләшә”, 2- “Тату Гаилә серләре”, 3- “Матур татар гаиләсе”, 4- “Исемең матур Олан”, 5-“Бирнәле кыз”, 6- Татарча чыршы бәйрәмнәре, 7-“Су буенда татарча дискотека”, 8- “Бии итек-читекләр”, 9- “Дәү әнинең күңел сандыгы”, “Шәҗәрә-чал тарихка тәрәзә”, “Төп йорт”, “Балаларыма васыят”. “Бишек җыры”, “Татар киемендә бүгенге көн”. Шушы эшләргә ярдәм итеп, мин акча түләп, “Сәгәдат хозуры – никях” дигән китап чыгардык. Без моны танышу клубында яшьләргә бүләк итеп бирәбез.

Шунысы сөенечле, элек мин район җитәкчеләренә кереп, әйдәгез сездә “Ак калфак” ачыйк әле, әйдәгез чара үткәрик әле тәрбияви дип йөргән вакытта, миңа бик авыр була иде, каршы киләләр иде. 2017 елда безгә ярдәм итә башладылар. Безнең чараларны ТНВ каналында карасагыз, анда күрәсез, хәзер хакимият җитәкчеләре дә чыгыш ясыйлар.

Миңа бик авырлык белән булса да 8 катлы йорт төзергә Аллаһ ярдәм бирде. Ә аның 1нче катын “Ак калфак” оешмасы куллана. Китапханә, үзебезнең милли китаплар белән танышу клубы, күргәзмәләр залы, тегү ательесы бар. Китапханәдә бүгенге көндә татар телендә 4 меңгә якын китап бар.

Ателье һәм китапханә булдыруга татар конгрессы зур ярдәм күрсәтте. Рәхмәт, Ринат Зиннурович! Бу ярдәмнәр безнең рухыбызны күтәрә, башка милләтләр арасында дәрәҗәбезне билгели. Шунысын әйтәсе килә, воскресная школа дибез, менә шушы китапханәдә без татар теле укытучыларын чакырыдык та, кем татарча укырга тели, олы яшьтәгеләр, бүген шунда дәрес алалар, үзләре түләп, билгеле.

Билгеле инде, чыгымнар минем өстә. (Уты, суы, җылылык, интернет, телефон, оргтехника, китапханәчегә түләү һ.б.г). Бүгенгесе көндә ателье кызлары үзебезнең бүлекчәләрне киендерәләр. Безнең кызлар чиккән калфакларны Татарстан, Оренбург һ.б. гына түгел Польша, Эстонияләр да кияләр.

Бүгенге көндә "Милли дизайн үзәге" ачу турында зур теләк белән янабыз. Итальян мастерлары белән сөйләшү алып барабыз. Берничә кыз аларда укырга теләк белдерде.

Төп проблема – бүлекчәләргә Башкортстан районнарында эшләү өчен бүлмәләр табу. Әкренләп хакимиятләр ярдәмләшә башлады. Балтач, Бишбүләк районнарында, Нефтекама шәһәрендә бүлмәләр бирделәр. Салават шәһәре "Әннәби" мәчете хәзрәте Рамил Насыйровка, Борай авыл мәчете хәзрәте Рифат Зариповка бүлекчәләргә эшләр өчен урыннар биргән өчен бик рәхмәтлемен.

Бүлекчәләрдә чараларга ир-атлар да актив катнаша башладылар.Үзегезгә алыгыз әле, "түбәтәй", - дип йөртерсез диләр. Була торган хәл. "Дәү этиләр" яисә "Яшь этиләр" клубларын оештырырга була!

Гомумән, Башкортостан татарларының әйтәсе фикерләре белән уртаклашасым килә. Республика казнасына кергән салымның өчтән бере татар исәбеннән туплануына карамастан, бүгенге көнгә кадәр аның филармониясе дә, курчак театры да, яшьләр театры да юк.

Башкортстанда татар әдәбияты проблемалары зур. Китап нәшер итү авырлыкларына турында: 2015нче Әдәбият елында – 11 китап бастырылса. Узган елда 10 китап. Быел исә тематический план буенча 9 китап чыгару каралган. Миллионнан артык татарның рухи ихтыяҗын бу басмалар белән генә канәгатьләндереп булмый. Шул ук вакытта һәр төбәктә шагыйрәләр, язучылар, рассамнар бар. Алар да үзләренең иҗат иткән бик матур шигырьләрен, әсәрләрен бастыра алмыйлар. Без, билгеле, шигрият кичәләре уздырабыз, тыңлыйбыз. Ул гына аз. Башка төбәкләрдә яшәүче милләттәшләр дә укысыннар, ишетсеннәр, танысыннар иде аларны.

Башкортстан Язучылар берлегендә бүген 273 язучы әгъза булып тора. Шуның илледән артыгы татар телендә иҗат итүчеләр. Быел Язучылар берлегенә 12 кеше кабул ителде. Шуның берсе татар, берсе урыс милләтеннән. Ел саен кабул ителүче милләттәшләр шул бер-икедән артмый. Безнең халык сәләтсез дияр идең, 20дән артык кеше берлеккә керергә үз чиратын көтә. Башта аларны әле сез яшь дип боралар, аннан сез карт инде диләр.

Дәүләт бүләкләре бирүдә дә татар язучылары һәм шагыйрьләре кыерсытылып килә. Әле бер генә татар язучысы һәм шагыйренең дә республиканың Салават Юлаев исемендәге дәүләт һәм Шәехзадә Бабич исемендәге яшьләр премияләрен алалганы юк. Гәрчә без аларны тәкъдим итеп торсак та. Хәтта халык шагыйре Әнгам Атнабаев та, бүген арабызда яшәгән халык шагыйре Марат Кәримовка да Салават Юлаев премиясе бирелмәде.

Әлбәттә, Уфада әдипләрнең исемнәрен мәңгеләштерү дә проблема булып кала. Дөньяның, Русиянең күп кенә шәһәрләрендә Тукайга һәйкәл булып та, без һаман да әле аңа ирешә алганыбыз юк. Башкала урамнарына татар шагыйрьләренең, язучыларының исемнәрен кушу да көнүзәк мәсьәлә булып кала.

Татарстан Республикасына рәхмәтебез зур. Форумнарга Башкортстан татарларына урыннар һәрвакыт бирелә. Татар яшьләре, татар эшкуарлары, татар галимнәре, дини форумнарда күпләп катнашып киләбез. Башкортстанга татар китаплары, дәреслекләр һәм методик әсбаплар белән ярдәм итү күләме бик зур.

Бездә Русиядә яшәүче татарларның саллы өлеше яшәвен искә алып, Бөтендөнья татар конгрессында Башкортстанда татар оешмалары белән эшләү өчен бүлек төзелде. Шул дүрт кешенең берсе мәгариф мәсьәләләре белән генә шөгыльләнер дип уйлыйбыз. Бу бүлеккә Башкортстанда мәгариф буенча махсус программа төзеп, эшләү кирәк булыр.

Алда шулай ук бергә чишәсе мәсьәлә, Татар теле һәм әдәбияты дәреслекләрен лицензияләү үзәге Казанда булырга тиеш дип исәплибез.

Барлык илдә татар теле һәм әдәбияты Казанда басылган китаплар буенча укытылырга тиеш. Уфада татар теле китапларын әзерләп чыгару мисаллары булды. Ул китапларны укытучыларның бер өлеше кире какты, чөнки аларда татар компоненты бик чамалы иде.

Берничә ел элек Башкортстандагы бер төркем галим Татарстан фәннәр академиясенә мөрәҗәгать итеп, Башкортстан буенча эшләү өчен бер бүлек оештыруны сораган иде. Уфадан торып анда эшләү өчен галимнәр җитәрлек. Без бу мәсьәлә дә хәл ителер дип өметләнәбез. Шулай ук Галимҗан Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм сәнгать институтында Башкортстан татар язучылары әсәрләрен өйрәнүне дә җайга саласы иде.

Без Татарстан Язучылар берлегенең дә статусын күтәрү яклы. Татарстан Язучылар берлеге Русиянең татар язучылары берлеге булып үзгәртелсә, без Башкортстанда аның бүлекчәсен дә ача алыр идек. Бу исә безнең, бер гомуми, әдәбият дөньясында кайнауны тәэмин итәр иде.

“Татарстан – Яңа гасыр” телевидениесенең Башкортстандагы бүлеген дә зурайтасы иде. Анда эшләүче ике кеше кыска хәбәрләр әзерләп кенә өлгерәләр. Без түгәрәк өстәлләр, аналитик тапшырулар да әзерләү өчен хәбәрчеләр бүлеген зурайтуны сорыйбыз. Башкортстан татарлары турында да милли кинофильмнарда төшерергә иде. Күрсәтергә иде безнең халыкны бар дөньяга!

**Васил Шәйхразиев:** Бик зур рәхмәт сезгә, Люция ханым! Бик матур чыгыш. Чыгыш ясау өчен сүз “Безнең мирас” журналы редакторы, язучы, җәмәгать эшлеклесе **Ләбиб Леронга** бирелә. Хактан да, без күптән түгел генә Башкортстанда, Уфада булдык. Татар гүзәле бәйгесе шунда булды. Безнең анда быел республика вәкиле Президентыбыз белән эшкә куелды. Шуңа күрә безнең милләттәшләр белән эшләү бик матур китте. Шуңа да бик зур рәхмәт! Рәхим итегез!

**Ләбиб Лерон:** Сүземне шигырь белән башлыйм.

Тел ачылгач, әйтә алсаң “әни” дип,
Тел ачылгач, әйтә алсаң “әти” дип,
Күзләреңә яшьләр тыгылмас.

Туган телең әле бу булмас.

Соң минутта әйтә алсаң “әни” дип,

Соң минутта әйтә алсаң “әти” дип,

Күзләреңә яшьләр тыгылыр –

Туган телең әнә шул булыр.

Бу безнең мәшһүребез Зөлфәтнең шигыре. Безнең шагыйрьләребез менә шушы телебез турында гомер буе борчыла килде һәм менә хәзер дә борчылабыз. Илдар абыйның бер шигыре бар. Аны да укып китәм. Икесе дә гыйнвар аенда туганнар.

Татарча туабыз,

Урысча “юабыз”,

Урысча беләбез,

Урысча көләбез,

Урысча уйныйбыз,

Урысча уйлыйбыз,

Урысча кочабыз,

Урысча эчәбез,

Урысча үбәбез,

Урысча сүгәбез,

Урысча ашыйбыз –

Урысча яшибез.

Урысча җырлыйбыз,

Татарча елыйбыз,

Татарча үләбез.

Татарча күмәбез.

Менә безнең бөтен язмышыбыз шушы шигырьдә әйтеп бирелгән. Әгәр исән булса, Зөлфәт абыйга гыйнварда 71 яшь тулган булыр иде, Илдар абыйга 85 яшь тулган блыр иде. Әгәр дә шушы мөнбәргә, шушы чарага Туфан абый кайтып, катнашкан булса, ул да бик нык борчылган булыр иде бүгенге телебез турында. Ул гомер буе шушы татар телен яклап чыгып,

чыгыш ясады зур мөнбәрләрдән. Һәм нинди аяныч хәлдә калганын аңлап, ул безне җәлләмәс иде, кызганган булыр иде безнең бүгенге хәлебезне.

Минем әйтәсе килгән сүзем шул. Бүгенге телнең вәзгыяте бар якка да китереп сукты. Ул минем гаиләгә бик тиз кереп килде. Минем хатыным татар теле укытучысы. Минем 3 оныгым бар. Ул минем онықларым аша китетерп сукмакчы була. Дөрес, минем 3 оныгым да татарча сөйләшә. Менә шушы яктан мин бераз сөенәм. Ләкин ничек укытырбыз, ничек булыр алга таба, тагын карарбыз. Чыннан да, без бетәбез дип елаудан, безне бетерәләр, безне үтерәләр дип шигырь язудан әллә ни алга китәлмәбез.

Роберт Әхмәтҗанов дигән зур шагыйрьнең мондый сүзләер бар иде, “Кысылдыңмы? Кычкыр. Кыстылармы? Кычкыр” дигән. Менә шуның шикелле, кысылдыңмы, татар? Кычкыр. Кыстылармы безне? Без кычкырырга тиеш. Кычкыру – акыру-бакыру турында сүз бармый. Ул эш-гамәлләр белән күрсәтелә. Менә сез монда җыелгансыз,  үз аңы белән татарлар җыелгансыз дип саныйм мин.

Сез менә шушы төбәкләрдә шушы эш белән янып йөрүчеләр. Шушы милләтем, халкым яшәсен иде дип янып йөрүчеләр. Мин сезнең алдыгызда чын күңелдән баш иям. Мин сезнең белән аралашып йөрим күбегез белән. Күбегез белән очрашып йөрербез алга таба да. Курганда да булдым мин, Свердлау да да булдым мин, Кулаткада да булдым мин, Пензада да булдым мин быел гына әле.

Бик күп хәлләрне беләм, татар мәктәпләрен күрәм. 69нчы елны ябылган мәктәпләрне Курганнарда күрдем. Татар авыллар нинди хәлдә икәнен күрәм. Күрәбез, кушылабыз, янабыз сезнең шикелле. Безнең дә йөрәкләр сыкрый, булдырган хәтле ничектер эшлисе, яшисе килә.

Менә безнең “Безнең мирас” дигән журнал чыгып килә. Менә сезгә күрсәтәм. Безнең дә хәлләребез хөрти. Безнең әле күпмедер дәрәҗәдә татар теле укытучыларыбыз бар иде. Алар безнең хәлебезне аңлыйлар иде. Безне пропагандалауда, шушы журналны алдыруда алар күпмедер эшлиләр иде. Ләкин мин беләм, татар теле укытучыларының да хәлләре мөшкел хәзер. Безне яклаганнарның да хәлләре мөшкел. Алар бу журналны да, “Казан

утлары” журналын да, “Мәдәни җомга”ны да алар инде күбесе яклый алмый, яздырта алмыйлар.

Менә монда безнең Сверлаудан Фәвия ханым Сафиуллина әйтте, безнең таянычыбыз Татарстан диде. Менә мин бүгенге мизгелдә таянычыбыз дип, сезне, төбәкләрдәгеләрне әйтер идем. Татарстанга гына без бик нык таяна алмыйбыз, үзебез Татарстанда булсак та. Мин, мәсәлән, инде 4 ел шушы журналның тиражын арттыру артыннан йөрим. Мәдәният министрлыгына да ничә тапкыр бардым инде.  Бүген иртән генә Гүзәл Азатовна белән сөйләштек.

350 журнал, “Безнең мирас” журналыннан алып, китапханәләргә тараталар Татарстанда. 350нең күпмесе барып җитә торгандыр, кайда ничектер, кайда икәү, кайда өчәүдер, бәлки. Ләкин мин бу журналны начар журнал дип әйтмәс идем. Кем укыган булса, белә. Бу журналда сез уйлаган уйлар, сез янган эшләр. Монда безнең татарның бай мирасы яктыртыла. Кулатканы аласыз икән ,Кулатка бар монда, Сверлауны аласыз икән, Сверлау бар монда. Сабаны аласыз икән, Сабаның Нырса авылы турында монда язылган, татар зираты турында. Пенза өлкәсе бар монда. Монда бөтен сезнең хикмәтләрегез бар, бөтен сезнең борчылган уйларыгыз монда бар. Мин сездән сорыйм менә шушы журналга булдыралган кадәр язылуыгызны.

Минем инде үзебезнең Татарстанлыларга ышанычым бетте. Районның бик күп хакимиятләрендә булганым бар. Бар безне бик нык аңлый торган хакимият башлыклары. Әтнә районында аңлыйлар безне, Кайбыч районында аңлыйлар безне. Азнакайда аңлыйлар безне. Ләкин кайбер районнарда безнең бер журналны да алдырмаганнар бар. Мин аларның замглавалары белән, русча әйткәндә, хакимият башлыклары белән, главалар белән, Аксубай районына ничә барып та, безнең эшебез барып чыкмый. Балык Бистәсе районында да безнең эшебез барып чыкмый. Балык Бистәсе районы главасы 46 урында икән, мин аларның бары тик матбугатка мөнәсәбәте, сәнгатькә мөнәсәбәтләре тискәре булганга күрә генә эшләре бармый дип уйлыйм.

Шуңа күрә, эшегез ныклап барсын өчен, җәмәгать, иң беренче чиратта матбугатны, сәнгатьне якларга кирәк. Сәнгатьле мирас, педагогик мирас, дини мирас, гомумән нинди мирасыбыз бар бу жуналда бар барсы да.

**Васил Шәйхразиев:** Бу журнал буенча, менә Гүзәл Азатовна монда, әйдәгез минем исемнән главаларга хат җибәрик. Бер караганда бу административный ресурс.

**Ләбиб Лерон**: Бик зур рәхмәт! Сезнең алдыгызда башымны иям.

Бары илем белән, телем белән бәхетле булам,

Илемнән дә, телемнән дә аера күрмә, Аллам!

**Васил Шәйхразиев:** Хөрмәтле милләттәшлә, җитәкчеләр! Без татар теле дигәндә үзебезнең гореф-гадәт дигәндә, һәрвакытта да дингә әйләнеп кайтабыз. Бүген безнең утырышта Татарстан Диния нәзарәтенең вәкиле катнаша. Ул безнең мөфти хәзрәтнең беренче урынбасары. Рөстәм әфәндегә мин сүз бирер идем. Әгәр дә мөмкин булса, регламент кысаларында, сезгә сүз бирү дөрес булыр дип уйлыйм.

**Рөстәм хәзрәт**: Әлхәмдүлилләһи раббил гааләмииин вәссаләәтү вәссәләәмү галәә расүүлиһил кәрим үә галәә әәлиһи үә әсхабиһи әҗмәгыйн. Аллаһу сөбханә вә Тәгаләгә безнең күңел түрләреннән чыккан мактаулар булсын. Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа (с.г.в.) безнең күңел түрләребездән чыккан салаватлар һәм сәламнәр булсын. Аның артыннан ияргән барча сәхәбәләргә Аллаһы Тәгаләнең ризалыгы булсын. Алар артыннан ияреп, Ислам дине буенча яшик әле, Аллаһы Тәгаләгә бәндә булыйк әле дигән барча мөселман бәндәләргә Аллаһы Тәгалә ярдәм бирсен.

Аллаһы Тәгалә үзенең рәсүле, Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа (с.г.в.) аша өйрәткән сәлам белән сәламлим. Әссәләмәгәләйкүм үә рахмәтуллаһ үә бәракәтүһ. Аллаһы Тәгалә һәрберебезгә вә һәммәбезгә сәламәтлек, тынычлык, иминлек насыйп әйләсен, рәхмәтеннән вә бәрәкәтеннән ташламасын, дөнья тормышыбызны да, ахирәт тормышыбызны да җәннәтле әйләсен. Дөнья тормышыбызны да, ахирәт тормышыбызны да җәһәннәм газабыннан, хәвеф-хәтәрләрдә, бәлә-казалардан Раббыбыз сакласын.

Безнең милләтебезне милләт иткән һәм безнең милләтебезнең милләт булуына үзенең зур өлешен керткән дин –ул ислам дине. Аллаһы Тәгаләгә шөкер, Аллаһ Тәгалә үзенең динен өйрәнергә безнең милләт балаларына үзебезнең ватаныбызны ташламыйча, өйрәнеп булу форсатын бирде. Үзебезнең илебездә, Татарстан җөмһүриятендә, мәдрәсәләребездә уку форсаты бар, әлхәмдүлилләһи шөкер.

Әлбәттә, хәзерге булган тенденцияләр ягъни безнең үзебезнең телебезне азрак кына аның куллануы азаю тенденциясе дини өлкәдә дә шулай ук бар. Мин үземнең милләтем татар милләте баласы буларак, безнең милләттәшләребезгә бер әйберне әйтәсем килә. Безнең милләттәшләребезнең бер өлеше үзебезнең туган телен дә, урыс телен дә һәм башка аның дөньясын һәм ахирәтен алып барырга кирәкле телләрне белә. Ике һәм аннан да күбрәк телләрне белгән милләттәшләребез бар. Алар әз түгел, ә шактый. Алар безнең милләтебезнең җәүһәрләре. Алар безнең милләтебезнең дипломатлары. Һәм икенче өлеше бар. Ул да булса, урысча гына белгәннәре, татарча белмәгәннәре.

Безне бөтенебезне берләштерә торган әйбер – ул да булса милли аң, үзебезнең милли аңыбыз. Менә кайберәүләребез чит илләрдән килеп, үзләренең илләрендә ул вакытта булган берничә йөз ел арасында телләрен югалтсалар да, милли аңнарын югалтмаган татар милләт балалары бар. Ул безнең илдә дә бар, башка илләрдә дә бар. Әгәр дә без киләчәктә Россия буенча бөтен мәчетләрдә татар теле түгәрәкләрен булдыра алсак иде, бик яхшы булыр иде дип уйлыйм.

Әлбәттә, бу бик зур максат кебек күренәдер, ирешеп булмаслык максат кебек күренәдер. Ләкин планлаштырылган рәвештә һәрбер мәчет имам-хатыйбы белән сөйләшеп, ул мәчет имам-хатыйбына шушы киңәшне әйтсәк кенә дә, минемчә, без Россиянең 60% мәчетләрендә татар теле түгәрәкләре булдыра алырбыз дип уйлыйм мин. Монад мин бернинди зыян күрмим. Ул дин тәгълимәтләренә дә каршы килми. Ул безнең динебезгә дә каршы килми. Ул безгә фәкать файдага гына була.

Әлбәттә, үземнең бу эштә үземенең өлешемне кертергә ял көннәрен менә шуның өчен корбан итәргә мин һәрвакыт әзер. Моны һәрберегез белергә тиеш дип уйлыйм мин. Аның турында әйтеп кенә калдырырга һәм аның барышы турында белештереп торырга. Белештереп торсаң, кызыксынып торсаң, әлбәттә, бу эш уңышка ирешәчәк. Бигрәк тә татар телен белмичә, аны белергә теләгән безнең татар балалары, татар баласы дигән сүз – татар кешесе, мәчеткә йөргән яки йөрмәгән татар кешесе, ул белергә тиеш, һәм мәчеттә татар теле түгәрәкләре бар икәнлеген, ул анда килеп, бу түгәрәкләрдә катнашып, үзенең телен барлый ала икәнлеген аңларга тиеш. Бу бик амбициоз, бик кирәкле гамәл. Әлбәттә, без моны эшләмәсәк, бездән башка моны беркем дә эшләмәячәк.

Мөфтиебез хәзерге мизгелдә Болгарда, җыенда катнаша. Шуңа күрә монда катнаша алмады. Шуңа күрә аның тарафыннан да сезгә зур сәламнәремне тапшырырга рөхсәт итегез. Әссәләмәгаләйкүм үә рахмәтуллаһ үә бәракәтүһ. Игътибарыгыз өчен рәхмәт!

**Васил Шәйхразиев:** Бик зур рәхмәт! Без әле үткән атнада Рөстәм хәзрәт белән Томск өлкәсендә Стрежевой дигән шәһәрдә, сөбханаллаһ, мәчетебезне ачып кайттык татарлар белән. Безнең анда автономия җитәкчесе Рамил әфәнде. Бик матур гына шәһәр хакимияте башлыгы, вице-губернаторлар, халык җыелып, ачып җибәрдек. Мәчетебездә 500 кеше ирләргә, 250 кеше хатын-кызларга. Шундый матур мәчет килеп чыкты шәһәрнең урта бер җирендә.

Менә бит, әгәр дә власть, хакимият ягыннан караганда, безнең авторитет ягыннан, карыйбыз, башта төзегәннәр чиркәү шәһәрнең урта бер җирендә. Аннары хакимият башлыгы шәһәрнең урта бер җирендә мәчеткә җир биргән. Сөбханаллаһ, мәчетне ачып җибәрдек. Халкыбыз йөри башлады. Шуңа күрә, хактан да, бу безнең телне, гореф-гадәтләрне, динне саклар өчен мәчетләребез зур эшләр эшлиләр. Аллабирса, декабрьдә безнең бөтен планнар барып чыкса, без Архангельскида тагын мәчет ачабыз. Хәзер Владивосток буенча чабып йөрибез. Анда вәгазь уку, татар телен саклап калу өчен безнең мәктәпләр, мәдрәсәләр һәрвакытта да кирәк булачак.

Мөхтәрәм җәмәгать! Безнең регламент буенча вакыт бетте. Язылганнарга чыгышлары өчен бик зур рәхмәт! Иң башта Ринат Зиннурович 2018 елга план турында сөйләде. Без аны алдык. Мин болай тәкъдим итәр идем, чөнки минем үземнең дә тәкъдимнәр бар бу план буенча. Сездән дә булыр дип уйлыйм. Мин мондый тәкъдим бирәм. Шушы планны без проект итеп хәзер кабул итик. Һәм 10 көн эчендә бөтен булган таләпләрне җибәрәсез безнең Исполкомга. Шушы 10 көндә бөтен булган тәкъдимнәрне Исполком карап, кирәк дип тапса кертә, кирәк дип тапмаса, нигә кертмибез дигәнен аңлатып бирә дә. 10 көннән соң шушы план миңа карарга кертелә дә, әгәр дә сораулар булмаса, раслыйбыз да һәм һәрбер җитәкчегә җибәрәбез, шулай ук үзебезнең Бөтендөнья татар конгрессы сайтына урнаштырабыз.

Шушындый тәкъдимгә ризасызмы?

Кем риза, кулларыгызны күтәрүегезне сорыйм.

Кем каршы?  Юк.

Битарафлар? 2 кеше битараф.

Күп тавыш белән кабул иттек. Бик зур рәхмәт!

Икенче сорауга күчәбез. Хөрмәтле милләттәшләр, Бөтендөнья татар конгрессына төрле оешмалар гариза белән чыга. Без алар өчен бик зур шатлык. Шул ук вакытта без территорияләргә карап, үзебезнең җитәкчеләр фикерләрен белеп, үзебез карап, карар кабул итәргә ашыкмыйбыз. Ныклап тикшергәннән соң гына бердәмлек булсын өчен, татар милләте өчен эшләрлек булсын дип кенә аларны үзебезнең конгресска кабул итәбез.

Чөнки безнең конгрессның иң зур 3 миссиясе бар.

1. Ярдәм кулы сузу
2. Берләштерү
3. Рәхмәтле булу.

Шул ук вакытта, бер гаризаны мин сезгә монда карар кабул итәр өчен игълан итәм. Ул безнең Мордовиядән. Документлары Исполком карады. Мордовия Республикасының “Татар эшмәкәрләре клубы” иҗтимагый оешмасы конгресска керергә тели. Һәм Исполком үзенең ризалыгын биреп, аның буенча карар кабул итәргә карар итә. Исполкомга

без ышанабыз, чөнки алар белән эшлиячәкләр, халык өчен дип. Шуңа күрә мин шушы иҗтимагый оешманы үзебезнең конгресска кушыр өчен сездән тавыш бирүегезне сорар идем. Кем риза, кулыгызны күтәрүегезне сорыйм.

Каршылар? Юк.

Битарафлар? Юк.

Бертавыштан кабул ителде. Рәхмәт!

Калганнарын әкрен-әкрен генә карап бирәбез, чөнки безнең “юк” дияргә мөнәсәбәтебез юк. Ләкин эшләргә кирәк.

## РЕЗОЛЮЦИЯ КАБУЛ ИТЕЛӘ

**Васил Шәйхразиев:** Теркәү вакытында сезнен һәрберегезгә дә резолюция проекты тапшырылган иде. Ул татарча һәм русча язылган. Мин шушы резолюция буенча шушындый карар бирер идем. Без хактан да, монда күп сөйләштек бүген. Дәүләт Советы сессиясе дә булды. Чыгыш ясаган җитәкчеләр дә үзләренең фикерен әйттеләр. Шуңа күрә мин шундый тәкъдим ясар идем. Моны үзебезнең карага алырга да, шушы 10 көн эчендә кемнең нинди теләкләре бар резолюциягә өстәргә. Булган фикерләрне уртага салып, Исполком карап, аннары инде Исполком шушы резолюцияне ярый дисә, имзабызны куеп, сайт аша һәм бүтән возможностьләр белән сезгә аны җиткерер идек. Шуның белән ризамы сез?

Ул чагында кул күтәрүегезне сорыйм.

Кем риза?

Каршылар? Юк.

Битарафлар? Юк.

Бертавыштан кабул иттек. Бик зур рәхмәт!

**БҮЛӘКЛӘҮ**

**Васил Шәйхразиев:** Ә хәзер бүләкләү өлешенә күчик. “Татмедиа” Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы һәм Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты 7нче тапкыр «Татар рухы һәм каләм» Бөтенроссия журналистлары һәм массакүләм мәгълүмат чаралары бәйгесен оештыра.

Ә хәзер җиңүчеләргә бүләкләр тапшырырга рөхсәт итегез.

*(Бүләкләү турындагы фәрманны Гөлназ Шәйхиева укый)*

***Бүләкләр тапшырыла.***

**VII «Татар рухы һәм каләм» Бөтенроссия журналистлары һәм массакүләм мәгълүмат чаралары бәйгесе**

*“Татар дөньясының тормышын һәм эшчәнлеген яктыртучы иң яхшы материаллар” номинациясе:*
1. Гыймадов Фаил Фәиз улы, «Болгар» радиосы;
2. “Яңарыш” мәгълүмати нәшрият үзәге.

*“Милли мирас” номинациясе:*
1. Шарова Луиза Николаевна, “Татарстан” журналы;
2. Хуҗин Илдус, «Саф чишмә» газетасы (Екатеринбург).

*“Милләт шәхесләре” номинациясе:*
1. Фәйзуллин Равил Габдрахман улы, “Казан утлары” журналы;
2. “Шәһри Казан” газетасы.

*“Татар дөньясының тормышын һәм эшчәнлеген яктыртучы иң яхшы фоторәсемнәр” номинациясе:*
1. Козловский Михаил Борисович, Татарстан Республикасы Президентының матбугат үзәге;
2. Галиев Рамил Якуб улы, “Татар-информ” агентлыгы.

Ә хәзер Дәүләт һәм Бөтендөнья татар конгрессы бүләкләрен тапшырырга рөхсәт итегез!

**«Татарстан Республикасының Атказанган матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелә:**

1. **Юнысова Әлфия Туфан кызы** – Бөтендөнья татар конгрессы рәсми сайтының мөхәррир–модераторы

**«Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исеме бирелә:**

2. **Гыйльманов Азамат Хәмитҗан улы –** Башкортстан Республикасы Дүртөйле муниципаль районының мәдәният һәм ял итү үзәге муниципаль бюджет учреждениесе директоры

**Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәте:**

3. **Галәветдинов Идеал Муса улы –** Самара өлкәсе татар "Дуслык" милли оешмасы әгъзасы

**Татарстан Республикасы мәдәният Министрлыгының "Мәдәнияттәге казанышлары өчен" күкрәк билгесе:**

4. **Шакиров Данис Фәнис улы** – "Бөтендөнья татар конгрессы" Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары, филология фәннәре кандидаты

**Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының Мактау грамотасы:**

5. **Нигъмәтуллина Гөлназ Әлфинур кызы** – Бөтендөнья татар конгрессы Республика иҗтимагый фондының Россия Федерациясе төбәкләрендәге татар иҗтимагый оешмалары белән эшләү бүлеге баш референты

6. **Кутузова Люция Азат кызы** – Бөтендөнья татар конгрессы Республика иҗтимагый фондының баш референты

**«Татар милләтенә күрсәткән олы хезмәтләр өчен» Бөтендөнья татар конгрессы иҗтимагый берләшмәләрнең халыкара берлеге медале:**

7. **Жехтунова Гөлзәлинә Заһит кызы** – Эстониянең Ида-Вирумаа татар мәдәнияте идарәсе әгъзасы (Эстония, Кохтла-Ярве).

8. **Хавыев Алмаз Альберт улы** - Пермь крае Кунгур шәһәре һәм районы татар-башкорт мәдәни үзәге рәисе.

9. **Хаҗипов Ясәви Таһир улы** - Ярославль өлкәсенең "Нур" Төбәк татар иҗтимагый берләшмәсе җитәкчесе.

**Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитетының Рәхмәт хаты:**

10. **Әхмәдҗанов Дияз Мәкъсут улы** – Әзербайҗан татар яшьләре үзәге рәисе (Әзербайҗан, Баку).

11. **Кадыйрова Эльмира Фәрит кызы** - Дагыстан Республикасының "Туган тел" татар иҗтимагый оешмасы җитәкчесе.

12. **Кузнецов Таир Сергей улы** – Бөтендөнья татар конгрессының Литва Республикасындагы вәкиле, Немежис татар җәмгыяте рәисе (Литва, Немежис).

13. **Латыйпова Индира Әбүзәр кызы** - Башкортстан Республикасы Туймазы шәһәре «Төмәнәк» татар тарихи-мәдәни иҗтимагый үзәге җитәкчесе.

14. **Мортазин Мөкатдәс Юрий улы** - Владимир өлкәсе "Бәхет" татар мәдәнияте үзәге рәисе.

15. **Сөнгатуллина Сәвия Җәләй кызы** – Казан шәһәреннән җәмәгать эшлеклесе.

**Васил Шәйхразиев:** Хөрмәтле милләттәшләр, регламент буенча 16.20 минутта бетердек. Шуңа күрә зур ихтирам белән чыгыш ясадык, тыңладык. Хактан да, безнең менә шулай очрашып, уртага салып сөйләшүләр бик кирәк үзебез өчен дә, халкыбыз өчен дә. Шуңа күрә без үзебезнең чыгышларыбызда ничек эшләгәннәребез, нәрсәләр безне борчый, кайда безгә ярдәм кирәк –

һәрвакытта файдасы булыр дип уйлыйм. Шул ук вакытта әйтәсем килә, безнең конгресс ягыннан, бөтен татарлар ягыннан без һәрвакытта да ачык. Без һәрвакытта да татарлар, татар халкы һәрвакытта да эшчән булган, һәрвакытта тырыш булган, бәхеткә лаек халык булган һәм бәхетле булган. Шуңа күрә менә бу безнең очрашуны хәзер бетерәбез. Сезгә барыгызга да бик зур рәхмәт! Иртәдән башлап, матур гына эшләдек, матур гына чыгыш ясадык, карарлар кабул иттек. Аны, Аллабирса, бергәләп барыбызда эшләрбез. Кайберләрегез белән без бәлки очрашмасбыз да. Без әйтәбез инде, алда Яңа ел, яңа өметләр, яңа бәхетләр булырга тиеш. Шуңа ышанып калабыз һәм бергә-бергә тырышып эшләрбез. Барыгызга да бик зур рәхмәт. Бәхетле булыйк. Гаиләләребездә һәрвакытта да тәртип булсын, үзебез дә, балаларыбыз да, оныкларыбыз да, оныкчыкларыбыз да татарча сөйләшсеннәр, татарча язсыннар, кирәк булса дога укысыннар һәм һәрвакытта да авыз тутырып “без татарлар” дип горурланып яшәсеннәр. Бик зур рәхмәт сезгә!